Сания Әхмәтҗанова

# Пар алма

*Шигырьләр*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2008

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2 Рос=Тат)-5
Ә87

**Әхмәтҗанова С.Ю.**

Пар алма: шигырьләр / Сания Әхмәтҗанова; кереш сүз авт. Г.Морат. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 159 б. — 2000 д. — ISBN 978–5–298–01688–9

Сания Әхмәтҗанова иҗатын шигърият сөючеләр беренче басмаларыннан ук яратып үз иттеләр. Бу китапка аның соңгы елларда язылган һәм күңелләрне битараф калдырмый торган шигырьләре тупланды.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2 Рос=Тат)-5

ISBN 978–5–298–01688–9
© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Әхмәтҗанова С.Ю., 2008

***Пар алмадай идек, багалмадай...***

*«Һәрбер сәнгать музыка булырга омтыла», — дигән бер акыл иясе. Бу җәһәттән шигырь белән көй-аһәңне игезәкләр дияргә дә ярый торгандыр. Шигырь — хис-тойгыларның визуаль сурәте булу өстенә төгәл музыкаль ритмга салынган, мәкам белән укыла-әйтелә торган дога-җыру да ул.*
*Кыскасы, һәртөрле иҗат җанга, күңелгә ятышлы булсын өчен, аның җырлап торуы мәслихәт.*
*Соңгы елларда җырлана торган байтак популяр җырларның текстларын иҗат иткән Сания Әхмәтҗанова да әнә бер шигырендә: «Җан авазым туа җырлар булып...» — дип яза. Шигырь-поэма да, нәсер-баллада да түгел, нәкъ менә җыр! Димәк, автор өчен җыр һич тә музыкаль төшенчә генә түгел, ул — кеше күңеленең барлык төс-сурәтләрен, әверелеш-тирбәлешләрен сынландыра торган иҗади хәл-халәт тә. Шуңа да бабаларыбыз юкка гына, җырның ертыгы юк, димәгәндер инде. Дөрес, халкыбыз әлеге тәгъбирне үзе чыгарган җырларга карата әйткән булгандыр. Халык җырларының, чыннан да, ертыгы юк шул.*
*Ә безгә үз гомеребездә җыр-көйләрнең нindiләрен генә ишетергә-тыңларга туры килмәде. Шигырьгә берниндi катнашы булмаган сүзтезмәләрне өч ноталы көйгә салып, шуларны көне-төне сәхнәләрдән яңгырата, радио-телевидениедән әйләндерә торгач, ниһаять, безләргә дә, Тукай бабайга кушылып, инде дә милләт тәрәккый итмәсә, дияргә калды бугай.*
*Дөресен әйтим, Сания Әхмәтҗанованың кульязмасы белән танышырга керешкәнче, күңелдә беркадәр икеләнү тойгысы да калкынып куйган иде. (Ни дисәң дә, җитмешләп җырның текстын язган автор бит!) Ә бераздан икеләнү-шикләнүләрне кызыксыну хисе, автор белән аның лирик каһарманын янәшә куеп, тәңгәлләштереп карыйсы килү теләге алыштырды. Чынлап та, кызык бит: инде дөньяны шактый танып белергә өлгергән, акыл утырткан, байтак еллар мөгаллимә булып эшләгән, ире белән ике егет тәрбияләп үстергән бу ханым иҗатта ни өчен шул дәрәҗәдә өзгәләнә, сызлана, юксына, сагышлана, моңая? Хикмәт нәрсәдә? Әллә инде автор белән лирик герой бөтенләй дә икесе ике кешеме? Юктыр дип беләм. Хәтта ки тормышта уйный алган очракта да шигырьдә уйнау мөмкин түгелдер. Әгәр кулыңа каләм алгансың икән, ул ахыргача ихлас булып калуны таләп итә.*
*Әллә автор һәрберебез диярлек күңеленең иң түрендә яшереп йөрткән, әмма ачыктан-ачык әйтеп бирергә базмаган хис-тойгыларны үзенеке итеп шигырь юлларына салганмы? Минемчә, менә шушы серлелеге белән Сания Әхмәтҗанова шигырьләре укучыда кызыксыну уята торгандыр да.*

*Йөрәгеңне куй син йөрәгемә —*
*Озак тормас бәхет, үтәр-китәр...*
*Соңгы кат күк татыйк сөю тәмен,*
*Үкенергә... калган гомер җитәр.*

*** * ***

*Зәгъфрандай, әйдә, саргаешмыйк,*
*Сабырлыклар сорыйк иң элек.*
*Дөньялыкта безгә кавышу юк,*
*Кавыштырыр, бәлки, мәңгелек...*

*** * ***

*Нәүмизләнеп күзгә карап торган*
*Мәхәббәтне ятим иттек бүген.*
*Синең белән минем юләрлектән*
*Бәхетебезнең чите китек бүген.*

*Сания Әхмәтҗанованың мәхәббәт шигырьләре сөю хатлары кебегрәк укыла. Хәер, авторның «Истәлек дәфтәре» рәвешендә бизәлгән, күзне, җанны иркәләрдәй югары полиграфик кимәлдә эшләнгән мәҗмугасын — «Оч иреккә, җырым!» дип исемләнгән тәүге шигырьләр китабын укыган кешеләр моны үзләре дә шәйләгәндер.*
*Саниянең шигырьләрен укыганда тагын шуңа төшендем: ул мәхәббәт, гыйшык-гыйшрәт турында күңелен җилбәгәй җибәреп яза алу тәвәккәллегенә ирешкән икән. Бу инде иҗатта үзенә күрә бер егетлек галәмәте саналырга хаклы.*
*Янә килеп, шунысын да искәртеп үтү кирәк: Сания Әхмәтҗанованың күпчелек җыр текстлары көй-музыкадан тыш та әдәби кыйммәткә ия, аерым шигырь булып яши алырдай әсәрләр. Сәнгатьнең иң гаммәви төрләреннән саналган җыр өлкәсендә ныклап шөгыльләнүче әһле каләм өчен монысы да бик мөһим.*
*Республика басмаларын, аерым алганда, «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» газеталарын, «Казан утлары», «Мәйдан» журналларын укып баручы шигърият сөючеләр Саниянең фәлсәфи җитдилек белән өретелгән, үзгә тембрлы, кем әйтмешли, җыр-көй кысасына «сыешмаган»*

*шигырьләре белән дә таныш. Болары инде Сания Әхмәтҗанованы яңа яктан ача. Аның лирик герое, үсеш-үзгәреш кичереп, үз дөньясыннан киңрәк мәйданга чыгып, милләтебез, телебезнең, рухи дөньябызның иминлеге өчен борчылып яши.*
*Соңгы вакытта язылган шигырьләренең берсендә ул:*

*Ярты юл да әле үтелмәгән...*
*Тукталырга, дускай, бик иртә.*
*Биштәреңне ерак куймыйча тор:*
*Сәфәр көтә безне, юл көтә, —*

*ди.*
*Сания Әхмәтҗановага да җырлы-шигырьле сәфәрендә яңа табышлар, иҗади күтәрелеш, бәрәкәтле озын юл насыйп әйләсен.*

*Газинур Морат*

Кешелегем

## Ялгызларга

Бар ул, беләм, ялгыз моңланганнар,
Сагышларда ялгыз янганнар.
Үз насыйбын — җаны теләгәнне
Көтеп-көтеп, ялгыз калганнар.

Юктыр, димим, парлар кавышканда,
Сиздермичә яшен сөрткәннәр.
Так яраткан өчен, язмышына
Җан түрендә рәнҗү йөрткәннәр.

Азмы әллә, үзе парлы булып,
Ялгызлыкта гомер иткәннәр!
Сез алардан күпкә бәхетлерәк,
Гомер буе тиңен көткәннәр.

Кызганмагыз, дисез, ник кызганыйм,
Бәхетле без, дисез, ышанам.
Сабырлыкка сезнең мин таң калам,
Горурлыкка сезнең сокланам.

*1999*

## Күз һәм без

Кырауга биреште күз яме,
Кышларга тапшырды язмышын.
Җирләрнең куенына баш салып,
Күз ала ахыргы сулышын.

Күзләрнең гомере бер түгел,
Китәр дә кайтыр ул әйләнеп.
Безләрнең язмышы торган күк
Пәрәвез җебенә бәйләнеп.

*Ноябрь, 2000*

## Бергә чакның кадерен белик

Бер-бер артлы, җепкә тезелгәндәй,
Көннәр түгел, безнең гомер үтә.
Туар таңның серле иртәсендә,
Белмим, кайгы,
Белмим, шатлык,
Белмим, тагын ниләр көтә?

Мин бит — сине, ә син мине таптың,
Кадерләрен белик бергә чакның.
Бергә чакның кадерләрен белик —
Бергә елыйк, әйдә, бергә көлик.

Ялгызымны бүген калдырма син,
Кара сөю тулы күзләремә.
Иртәгә дә көн бар әле, димә!
Бүген шаярт,
Бүген ярат,
Бүген күм син назлы сүзләреңә.

Ике йөрәк бергә тибәр өчен
Дөнья ваклыклары түгел киртә.
Тәрәзәгә шаян җилләр булып
Әллә яшьлек,
Әллә картлык,
Әллә узган гомер чиртә.

*2000*

## Тормыш киносы

Йөгерергә чыктым — үзгәрергә:
Күренәсе килә яшь булып.
Сау-сәламәт күренәсе килә.
Йөрәк чаба алдан, ашкынып.

Даруымны бүген эчми тордым —
Саф һавадан алыйм сихәтлек.
Бәлзәм булып җанга ятсын әле
Бу иртәнге салкын рәхәтлек.

Балыкчылар ярга сибелгәннәр,
Пеләшләрдән күзләр чагыла.
Әзмәвердәй бер ир эт җитәкләп
Кайтып килә шәһәр ягына.

Колагына плеер тыккан малай
«Девятка»сын юа тырышып.
Нинди җыру алыштырды икән
Таллыктагы кошлар тавышын?!

Яр буенда ике исерек (?) кызый
(Туташ, дисәм, телем әйләнми)
Шырпы сорап тора, ярга чүккән
Бөкре балыкчыга бәйләнеп.

Кичтән кайтмый калган маллар кебек,
Адашканмы, калып «көтү»дән.
Кичә-бүген бергә буталганмы
«Кәеф»ләнеп бәйрәм итүдән?

Ак яулыклы әби шешә җыя.
Берне тапты: куйды сөенеп.
Бүген кабар сыныгын эзли булыр,
Куак төбе саен иелеп.
Йөрәк алды чәнчеп: үз урынында —
Мине ташлап, кая киталсын.

Чирем артты, күреп ун минутлык
Хакыйкати тормыш киносын.

*2000*

## Хуш хәзергә...

Яшәргәнсең, диеп сокланмагыз —
Күз тиюләр аягымнан егар.
Бәхет тапкан, диеп уфтанмагыз —
Куркып, куенымнан очып чыгар.

«Шигырьләрең үзең турындамы?» —
Урынсызга ошбу соравыгыз.
Ялгыш кына юш килмәсен тагын
«Ялгыздыр ул» дигән юравыгыз.

«Җырың моңлы!»
Моңсыз җыр туамы?
Моңлырагын әле язасым бар...
Хуш хәзергә, барыр юлым ерак —
Үз җырымны эзләп табасым бар.

*2000*

*** * ***

Мин яңадан тудым бу дөньяга,
Ташны тишеп чыккан үлән мин.
Тоткынлыкның ни икәнен аңлыйм,
Яшәү тәмен хәзер беләм мин.

Сусынымны басар өчен аз шул
Тик күтәреп яуган ләйсәннәр.
Мин Кояшка үреләм, җылы эзләп,
Әрсез, диеп, әйдә, әйтсеннәр.

Булыр башка басып китүчеләр,
Иючеләр булыр башын да —
Нәфис кенә үзе, ләкин, күрче,
Тишкән, диеп, кыя ташын да...

Мин яңадан тудым бу дөньяга...
Эзли торгач, таптым үземне.

*2001*

*** * ***

Шигырем, дускаем, ничекләр син булдың?!
Сыйдырдың яхшысын, яманын.
Чарасыз калганда, күңелнең китеген
Иң кирәк сүз белән ямадың.

Каләмем, ташлама! Шигырем, туктама!
Үз туган телемдә сайрап тор!
Дустымның җанына шифа бул, сихәт бир,
Дошманга кылычың кайрап тор!

*2000*

## Исәнме, яңа көн!

Тормыш бигрәк катлаулы, дип

Зарланырга вакыт тар.
Минем әле, жиң сызганып,
Зур эшләр башлыйсым бар.

Исәнме, яңа туган көн!
Баш иеп сәлам бирәм.
Каршылыйм сине, шатланып,
Изге ниятләр белән.

Әле кичәге көнемнән
Гыйбрәтләр аласым бар.
Ялгышларымны төзәтеп,
Сафланып каласым бар.

Заманадан калышмыйм дип,
Яшендәй яшьнисем бар.
Шушы бәхетле көнемне
Сагынып яшисем бар.

*2000*

## Җырчы кош

Очам диеп күтәрелгән кошның
Тотып канатларын кистеләр...
Кемнәр диген — күккә меналмаган,
Очалмаган түбән хисләләр.

Бәгыренә туңнар булып катты
Әйталмаган рәнҗү-каргышы.
Көнләшерлек иде аның җыры —
Шушы булды иң зур «ялгышы».

Яңа гына канат чыгып килгән
Бер кошчыкны күккә чөйделәр;
Җырчы кошның канатларын биреп,
Оч биеккә, сайра, диделәр.

Үземнеке диеп сузды җырның
Чит берәүдән отып алганын.
Кемдер сизде, кемдер «аңламады»
Бу кошчыкның матур ялганын.

Ә җырчы кош җирдә ятып калды,
Ашкынса да җаны биеккә.
Елый-елый шушы җырын язды,
Сабак итеп үзе кебеккә:

«Очар күге түбән булганнарга,
Бәя сорап, җырың җырлама.
Син биектә, алар түбән булгач,
Җырың аңларлар дип уйлама».

Басыла төшкәч әрнү-рәнҗүләре,
Үзен-үзе кошым юатты.
Үзәк өзгеч моңлы җырын җырлап,
Үзе кебекләрне елатты.

Сайрар урыны күктә булмаса да,

Җаны мәңге түбән булалмас.
Канатларын кисеп атсалар да,
Җырын беркем тартып алалмас.

*2000*

## Кычкыра күке, кычкыра

Һәр көн иртән кояш чыга,
Җиһан нурга коена.
Шушы бәхетле мизгелләр
Мәңгелек күк тоела.
Кычкыра күке, кычкыра,
Санап кемнең гомерен?
Кояшлы һәрбер иртәнең
Белеп яшик кадерен.

Күрешүләр көтә-көтә,
Хушлашыр вакыт җитә.
Бу дөньядан күпме җаннар
Бәхиллек алмый китә...
Кычкыра күке, кычкыра,
Санап кемнең гомерен?
Шатлыклы һәр очрашуның
Белеп яшик кадерен.

Төн куенына башын салып,
Күз йома тагын бер көн.
Яхшымы ул, яманмы ул, —
Кайтара алмый беркем.
Кычкыра күке, кычкыра,
Санап кемнең гомерен?
Һәрбер йөрәк тибешенең
Белеп яшик кадерен.

*2004*

## Гыйнвар төне

Гыйнвар төне. Җанда — эңгер-меңгер,
Йокымсырый мидә уй күче...
Сикереп торып дәштем үз-үземә:
«Мәрткә китәсең бит, әй, Кеше!»

Калҗаң майлы, ятар урының җайлы,
Тәрәзәң дә тавыш үткәрми.
Ишегеңдә җиде катлы йозак —
Күршең түгел, хәтта бур керми.

Дөнья шавы бераз айнытмасмы —
Нигә күңел күзең ачмыйсың?
Җан йозагың охшый күгәргәнгә,
Ерак аттың микән ачкычын?

Бу син түгел. Син башкарак идең,
Таш битлек бит гамьсез йөзеңдә;
Элеккечә моң дәрьясы түгел,
Кипкән кизләү нурсыз күзеңдә.

Дула, буран! Ыжгырыгыз, җилләр!
Миңа уяныrга кирәк, кыш!

Тоткынлыкта, күкрәк читлегендә
Бәргәләнеп сула шигырь-кош.

Китерегез кәгазь-каләмемне,
Сырхау күңелемә шул дәва...
Ярты юлда калган җырым булып,
Бәгыремә саркып моң сава.

Гыйнвар төне... Күздән йокы качты...

*2004*

## Икетеллелек

Бер казанга сыймый диләр ике башны,
Кемгә хаҗәт чиле-пешле тәкә башы?!
Безнең казан ташыса да, кайный бирә,
Пешә ашы, берүзенә ике башы.

Ике тел дә сыя безнең бер авызга,
Һәр икесен тигез дибез, бердәй хаклы.
Кайсын гына тешләсәң дә, бик авырта —
Икесе дә дәүләт теле, халык яклы.

Бер казанда кайнасак та, бер үк утта,
Кемдер әйтер: хокуклар, дип, безнең башка.
Телләрнең, дип, берсе — олы, берсе — кече,
Тик берсенең языла, дип, сүзе ташка.

Туган телең оныт, диеп кем боера,
Авызыңа кем соң көчләп хәмер коя?
Намазлыгың йолкып алып тез астыңнан,
Саф әхлаклы булма, диеп кемнәр тыя?

Хөсетлектән ашый күрмә күршең башын,
Үткенлим дип, кыя күрмә үз телеңне.
Мин татарга урын тар дип бу казанда,
Килмешәккә бирә күрмә үз түреңне.

Кайда синең татарлыгың-хәтәрлегең?
Дөньяларны дер селкеткән даның кайда?
Түрәләрне эттән алып, эткә салып,
Хәл мөшкел, дип зарланудан нинди файда?

Бер казанга сыйдырыйк без ике башны,
Ике телнең берсен кисеп, сакау булмыйк.
Татар башын татар ашар, дип сайраучы
Тукай әйткән бер чүрәкәй тартар булмыйк.

*26 апрель, 2005*

*** * ***

Бераз гыйбрәт алсын, диеп,
Балам кеше булсын, диеп,
Әткәң-әнкәң, укып дога,
Озаттылар сине юлга.

Көне үтсә, төне озын —
Шәһәр сыный авыл кызын.
Урамның бар кырык күзе —
Кызармаслык булсын йөзең.
Аңладыңмы, балам, сүзем?

*2005*

## Гадел хаким

Ышанмасаң әгәр бүгенгемә,
Шик тудыра икән узганым, —
Синнән түгел, оят үз-үземнән:
Гадел хаким бары вөҗданым.

Чынлап түгел, фәкать уйларымда
Булса вәгъдәбезне бозганым, —
Синнән түгел, оят үз-үземнән:
Гадел хаким бары вөҗданым.

Кеше бәхетенә нәфес сузсам,
Бәхил кылмый тәкъдир язганын, —
Синнән түгел, оят үз-үземнән:
Гадел хаким бары вөҗданым.

*16 ноябрь, 2005*

## Кешелегем

Кеше икәнеңне кешелекле
алымнар белән исбатлау кыен.
*Кемдер әйткән сүзләр*

Сукыр төннең күзенә багып, нәрсә көтәм?
Көпә-көндез шәм яндырып, кемне күзлим?
Кешелегем чыгып качты мине ташлап,
Арлы-бирле йөгерә-чаба шуны эзлим.

Белдерүләр язып элеп карыйм микән?
Табылдыклар бүлегенә барыйм микән?
Кеше хәзер акча өчен җанын сата —
Кешелекне әллә сатып алыйм микән?

Әгәр берәү ишетә калса сүзләремне,
Тилергәндер бу мескен, дип уйлап алыр.
Җавабым шул: бүген мине кеше итеп
Саклап калса, кешелегем саклап калыр.

*10 ноябрь, 2006*

## Төен

Нәфеснең азуын йөрдем
Сылтап заманасына.
Бәйләргә вакыт күңелне
Иман манарасына.

Үрелгән бавым җидедән —
Һәр җебе нәфес яклы.
Чишелеп китүдән күңелне
Бары вөҗданым саклый.

Бер җебе бауның — мин-минлек —
Дөньяга баш булмакчы.
Икенчесе — хөсетлегем —

Җанны талкып тормакчы.

Өченче җеп — саранлыгым,
Байлыкка табынуым.
Дүртенчесе — гөнаһларга
Сөртенеп абынуым.

Бавымның бишенче җебе —
Ялкаулык шаукымчысы.
Комсызланып ашау-эчү —
Җебемнең алтынчысы.

Җиденче җеп — ачу саклау
Дустыма-дошманыма,
Үчләнеп каршы чыгуым
Намусым кушканына...

Нәфесемне мин бүгеннән
Бәйләп куям төенгә:
Җиңдем тагын берәүне дип,
Шайтан мәлгунь, сөенмә!

*10 ноябрь, 2006*

## Иманыңа куәт сора

Корым сарса бу җаныңа, юшкын ятса,
Мөлдерәмә күңелеңне хәсрәт басса,
Күз яшьләрен хәерлегә бары юра, —
Елый-елый иманыңа куәт сора.

Яны белән борылып басса дус-ишләрең,
Гел кирегә китеп торса бар эшләрең,
Булыр-булмас бәндәләргә башың орма, —
Сәҗдә китеп, иманыңа куәт сора.

Ашыкмый тор. Җиде ятка бәйләнгәнче,
Якын кешең чит кешегә әйләнгәнче,
Өр-яңадан тормышыңны башлап кара, —
Кыйблаң үзгәрт... Иманыңа куәт сора.

*25 ноябрь, 2006*

## Аңла, балам...

Илен, телен, динен алмаштыра —
Ниләр көтә адәм баласын?
Аңла, балам, сине Үзең итеп
Туган телең саклап каласын.

Куштым сиңа сайлап матур исем —
Җисемеңә туры килсен ул.
Милләтеңнең бер мирасы итеп,
Әткәң-әнкәң биргән исем ул.

Заман белән бергә үзгәрә бел:
Телләр өйрән, балам, дөнья күр.
Йөз чөермә ләкин үз телеңнән,
Бу — Ватанны сату белән бер.

Син тугач та, ана сөте белән
Иренеңә тамган туган тел.
Туган телең җуйсаң, әнкәеңне
Онытуың булыр, балам, бел!

*7 декабрь, 2006*

## Кабан елы

Эт елына алмаш булып
Кабан елы ашыга.
Юраган юш килә, диләр,
Юрыйк, әйдә, яхшыга.

Без яшәп күнеккән инде
Терек-терек элдереп.
Дуңгыз син, дип сүккән саен,
Танау белән җир сөреп.

Башны аска иеп йөрмик,
Мыркылдамыйк юк-барга...
Мөмкин ишәю ягыннан
Чучкаларга охшарга.

Елы шундый, дип акланмыйк,
Кылган саен явызлык.
Кеше булып кала белик,
Котыртса да дуңгызлык.

Килсен, әйдә, Кабан елы
Төкле аягы белән.
Чыдам сырты, күндәм холкы,
Муллык-байлыгы белән.

*29 декабрь, 2006*

* * *

— Хәзер болай сөйләшмиләр,
Хәзер болай эшләмиләр,
Хәзер болай яшәмиләр, —
Дөньядан артта калгансың син, әни!

— Сөйләгән сүзең ятышлы,
Эшләгән эшең уңышлы, —
Һәрбер адымың отышлы, —
Кайлардан мондый булгансың син, балам?!

*7 февраль, 2007*

## Белмәү кирәк

Күзгә карап алдалыйсың, ант итәсең, —
Ялганыңны сизеп торам, аңлап торам.
Бер мизгелгә ышанып та куя язам:
Хак сөйли, дип, үз-үземне алдап торам.

Чын дөресен әйтә алу — батырлык шул,
Синдә, дускай, ни кызганыч, куян йөрәк.
Һәм шуңарга куаныплар бетә алмыйм —
Бүген миңа дөреслекне белмәү кирәк.

*29 март, 2007*

## Аерылу

*Камиләгә — әтисеннән*

Янәшәдән өчәү атлап килә,
Ап-ак карда кала өч пар эз.
Тукталдылар эзләр аерылырга —
Өзгәләнмә, йөрәк, зинһар, түз.

Нәни кызчык карый әтисенә,
Мөлдерәтеп яшьле күзләрен.
Телсез калган ата, өнсез калган —
Әйтә алмый соңгы сүзләрен.

Кысып алып кызын күкрәгенә,
Үпте бары тозлы күзеннән.
Үзенең дә ачы күз яшьләре
Тәгәрәде ап-ак йөзеннән.

Мәхәббәт һәм нәфрәт ник янәшә?
Никах вәгъдәләре, сез кайда? —
Җавабыгыз күптән әзер дә бит,
Тик сабыйга моннан ни файда?

Вакыт оныттырыр кайгыгызны,
Сез беразга гына түзегез...
Чит кешегә «әти, әтием» дип
Дәшә алыр микән кызыгыз?

Кызчык үсәр, үсәр үги булып.
(Булмый үги ир дә, хатын да!)
Бәхетлерәк бәхет сайлап йөреп,
Онытмансыз бала хакында.

Бар галәмгә ярсып кычкырсаң да,
Үзгәрми шул берни, йөрәк, түз...
Башка юлдан китте, аерылып,
Ике пар эз — ана белән кыз.

*2 апрель, 2007*

## Моңаймале ялгыз, и балам...

Күзләреңә туры карый алмыйм —
Карашларың җанга ут сала.
Газиз башкаеңда нинди уй бар,
Никләр болай моңлы син, бала?!

Җырлавыңны тыңлап, йөрәк туктый,
Күкрәгемдә каба сулышым...
Еламыйча түзәр хәлләрем юк —
Никләр болай моңлы тавышың?

Кушылыймчы мин дә җырлавыңа,
Булмасам да җырчы сандугач.
Бардыр әле уртак көйләребез,
Зарлы уйларыбыз пар булгач...

Күкрәгемә куй син башкаеңны —
Ярты сагышыңны мин алам.
Бергә-бергә барыбер җиңелрәк,

Моңаймале ялгыз, и балам!

Сузып-сузып уйна гармуныңны,
Күңелеңдә төер калмасын.
Җырлый-җырлый, елый-елый юыйк
Үкенүләрнең тирән ярасын.

*5 май, 2007*

## Сәфәр

Һәркем эзли җирдә үз кыйбласын,
Иртәге көн тәкъдир кулында.
Язмыш кичеп йөргән юлаучы без,
Мосафир без гомер юлында.

Ярты юл да әле үтелмәгән...
Тукталырга, дускай, бик иртә.
Биштәреңне ерак куймыйча тор:
Сәфәр көтә безне, юл көтә.

Якты өметләрне кабызыйк та
Җылытыйк бер арган җаннарны.
Бәхет яши торган тарафларга
Юлны дәвам итик аннары.

Әле генә таң сызылган иде,
Инде кояш байый офыкта.
Таулар менеп таулар төшәсе бар
Гомер дигән кыска вакытта.

*Гыйнвар, 2008*

## Парлы гомер

Зәңгәр күктә уйный пар күгәрчен,
Пар аккошлар йөзә күлләрдә.
Бер-берсенә сыенып үссә генә
Шаулап чәчәк ата гөлләр дә.

Сыерчыклар бала очырганда,
Ни куаныч, күзләр тимәсен!
Кошларга да әти-әни булу
Көтеп алган шатлык, күрәсең.

Табигатьтә язын — туйлар чоры,
Һәр бәхетле җанның пары бар...
Алтын көзгә керә җитәкләшеп
Тигез гомер иткән парлылар...

Парлыларның сабырлыгын язмыш
Сыный икән, әйдә, сынасын.
Парсыз итеп кенә яратмасын
Бу дөньяга адәм баласын.

*28 февраль, 2008*

# Саумы, яшьлек!

## Аклык

Белмим, әллә кыш сәбәпче:
Күңелдә никтер аклык.
Салкын карны эретерлек
Хисләрдән учак яктык.

Кар-йолдызлар учлап алып
Зәңгәр күкләргә сибәм.
Кояш нурларын тотмакчы —
Ашкына күңел нидән?

Онытткык бар үпкәләрне,
Шатланыр сәбәп таптык.
Кыш микән лә сәбәпчесе —
Күңелдә бары аклык...

*1981*

## Кил генә

Җаннарыңа дәва кирәк чакта
Ялгыз көннәреңә керт мине.
Нигә килдең, диеп сорау бирмә,
Кайнар сулышыңнан эрет мине.

Үкенмәссең, миндә син белмәгән,
Син көтмәгән сихри тылсым бар.
«Сөелдем» һәм «сөйдем» диюләрең
Көлеп сөйләр өчен калсыннар.

Хәмер эчмичә дә баш әйләнер
Мизгелләрне бүләк итеп ал.
Башкайларың ташка орма әле —
Кайнар күкрәгемә минем сал.
Күктән төшкән изге фәрештәдәй,
Гөнаһларың гафу итәрмен.
Күз яшьләрең, борчу-хәсрәтләрең
Үзем белән алып китәрмен.

Җаның куяр урын тапмаганда,
Сәбәпләрен эзләп тилмермә —
Бер сүз әйтмәсәң дә, аңлармын мин —
Хәбәр биреп торма, кил генә.

*7 ноябрь, 1996*

## Ачы язмыш

Бәллүр касәләргә салып эчтем
Язмышымның әче шәрабын.
Белалмадым, затлы шәраб эчеп,
Сусау басылмауның сәбәбен.

Вакытлыча башлар әйләнсә дә,
Дәвасы юк никтер йөрәккә.
Башым чатный, уйлар пыран-заран,
Юк-бар сорау биреп йөдәтмә.

Язмышымны азлап-азлап йотам,

Арта гына бара әчесе.
Йөзне чытып, тешләремне кысып,
Эчәсе дә әле эчәсе.

*1997*

## Ни булса, шул!

Тәрәзәмә бер кош килеп кунды.
Ник яралы аның канаты?
Тәрәз аша үзәк өзгеч тавышы
Бәгыремне тырнап канатты.

Тән ярасы җан ярасы түгел,
Бер төзәлер әле ничек тә...
Син иреклe, кошым! Минем җаным
Ачылмаслык тимер читлектә.

Анысы алай озак тоталмаслар
Үз-үземнән мине аерып...
Ни булса, шул: ачам йозакларын,
Теш-тырнагым белән каерып!

*1997*

## Чынлап шаяру

Җитәр инде, күп еладым
Үпкәләткән чагыңда.
Бүген берни булмагандай
Басып торам яныңда.

Елмаям шул, нигә әле
Гаҗәпләнеп карыйсың?
Син бит минем бер тамчы да
Күз яшемә тормыйсың!

Беләсеңме, гафу итәм
Барысы-барысы өчен дә.
Син әлегә чит түгелсең,
Түгел якын кешем дә.
Кызганырга калды бары
Сыкрап үткән гомерләр...
Сукмагыбыз гел янәшә,
Аерылды күңелләр...

*1997*

## Күңелемнән күңеленә

Күңелемнән күңеленә
Җырларымнан салам сукмак.
Гөл-чәчәкле аның як-ягы.
Тукталыйк та «Сөю» дигән
Могҗизалы аланнарга,
Өзик чәчәкләрнең акларын.

Синең белән миннән башка
Бу сукмакны беркем белмәс,
Булсын әле уртак серебез.

Онытып бар дөньяларны,
Санамыйча минутларны,
Бер яшьлеккә кайтып килербез.

Күмелеп гөл-чәчәкләргә,
Бәхет үзе яши монда,
Безне көтеп серле аланда.
Күңелеңнән күңелемә
Табарсың дип сукмакларны,
Өметемне өзмим һаман да.

*13 декабрь, 1997*

## Хәтәр төш

Пардан ап-ак күлмәк кигәнбез,
Ак атларда икәү киләбез.
Бөтен дөнья никтер ак икән,
Үзе ташу аккан чак икән.

Елгада боз чатнап ярыла,
Син — ташуның аргы ягында.
Бата-чума боздан атладым,
Чыгалмады ярга атларым.

Дәшеп карыйм — чыкмый тавышым,
Барыр юлларымны ялгыштым.
Янәшәдә үзең, янымда,
Тик минеке түгел һаман да.

Ак томанга кереп югалдың,
Юлларыңа ятып еладым...
Ярый әле тышта кыш икән,
Югалтулар бары төш икән.

*Гыйнвар, 1998*

## Килә үзем булып каласым

Үзгәртергә мине соң шул инде —
Үземнән дә яхшы булалмыйм.
Авыр, нишлим, дөресен әйтүләре,
Яратмагач, «сөям» диялмыйм.

Тыңламыйсың, диеп үпкәлисең,
Тыңлыйм үзе, бары ишетмим.
Башка берәү булган йөрәгемә
Сыйдыралыйм сине ничек мин?

Сиңа карыйм, ләкин аны күрәм,
Син янымда, ләкин үз түгел.
«Сөям» дию, күңел күрү өчен,
Әйтеп оныта торган сүз түгел.

Килми сине утка саласым,
Килә үзем булып каласым.

*20 сентябрь, 1998*

## Мәхәббәтем гафу итәр микән?

Ничә төннәр инде таңга кадәр
Тәрәзәмдә ялгыз ут яна.
Бигрәк үкенечле — таңы атмас
Төннәр булып килдең син миңа.

Мәхәббәтем гафу итәр микән?
Мин язларны хәзер кұралмыйм.
«Сөям» дигән сүзләреңә каршы
«Мин дә» диеп җавап биралмыйм.

Җиңел мәллә дәшми торулары —
Сорау арты сорау юллама.
Акылым җуеп, беркөн «әйе» дисәм,
Хак булса да, зинһар, тыңлама.

Чәлпәрәмә килгән өметемнең
Өлешләрен җуйдым күптән мин...
Чит берәүне син дип кабул иткән
Йөрәгемә генә үпкәлим.

*1998*

## Җәй

Таш күлмәген кигән шәһәр өен
Җәйге кояш тормый кызганып.
Мөмкин булса, ул да безнең арттан
Китәр иде әллә кузгалып.

Җәй, җәй, җәй! Сагындырдың, әй!
Юлыбызга хәтфә келәм җәй.
Синең килүең сагынып көттек,
Ачуланма, шәһәр, без киттек.

Чәчләреңнән чәчәк исе килә,
Хушбуй түгел, җилләр исе ул.
Битләреңнең очы алсуланган —
Истәлеккә кояш төсе ул.

Бала-чага ялантәпи чаба,
Яшь-җилкенчәк туймый шаярып.
Җәйгә чыккач, хәтта карт-корылар
Таягына тормый таянып!

*1998*

## Мин бәхетле булыр өчен тудым

Бу дөньяга күпме кеше килгән,
Бардыр тагын күпме туасы.
Мин — әнкәмнең Ходай сөеп биргән
Газизләрдән газиз баласы.

Гомеремнең серле китабында
Булыр димим битләр ак кына.
Язмыш бит ул күпләп камчы суга,
Ә башлардан сыйпый чак кына.

Җил-яңгырлар тими үстем шул мин,
Давылларга ничек чыдармын?

Ялгышып та берүк рәнҗетмәгез,
Иркә гөлдәй юкса сулырмын.

Сөю-назга сусап туйганым юк,
Нәкъ нарасый сабый инде мин.
Бу дөньяга елар өчен түгел,
Көлеп яшәр өчен килдем мин.

Гомер китабымның соң битен дә
Тик елмаеп телим ябарга.
Мин бәхетле булыр өчен тудым
Һәм Берәүнең бәхете булырга.

*1998*

## Тәүге кар

Дөнья ап-ак, күңел хуш,
Сагындырган икән кыш.
Тәрәзәгә күзең сал,
Тәүге карны күреп кал.

Карлар төшә серләшеп,
Безгә шатлык өләшеп.
Үтә гомер шул карларның
Пакьлегеннән көнләшеп.

Юләрем син, дип көлмә,
Бу бит ялган кар, димә.
Көзнең көне санаулы,
Кышка да күп калмады.

Күмеп кара төсләрне,
Назлап якты хисләрне,
Күкләрдән иңә аклык,
Безләргә теләп сафлык.

*1998*

## Тормыш — тамаша

Пәрдә ачыла, утлар сүнәләр,
Җансыз курчаклар терелә шулчак.
Уйлап карасаң, тормыш — зур сәхнә,
Синең кулыңда мин — җанлы курчак.

Пәрдә ябыла, утлар кабына.
Монда мәхәббәт җиңә һаман да.
Сәхнәдә гомер алдан язылган,
Ә минем язмыш синең кулыңда.

Тормыш-тамаша гел шулай барса,
Аны үзгәртеп үзем язармын.
Синең урынга, әй, төп уйнаучым,
Башка берәүне эзләп табармын.

*13 декабрь, 1998*

## Мәхәббәт җимеше

Бу ни хәл бу? Көз җитсә дә,

Шау чәчәктә, карачы.
Хыялымның бакчасында
Бер мәхәббәт агачы.

Берәү генә, янып тора,
Һай, җимеше югары.
Көз җитсә дә, кыш кермәгән,
Өмет өзмим, юк әле.

Җан сусавын басалмагач,
Оныт шуны, димә син.
Бәлки, беркөн учларыма
Үзе төшәр, белмәссең.

Күңелемнең бар җылысын
Аңа саклап йөретәм.
Ул бит Сөю агачында
Өзелмәгән Өметем.

*19 гыйнвар, 1999*

## Зәңгәр күлдә

Табигатьнең, кызлар күңеледәй,
Дәрт ташыган гүзәл мизгеле.
Җәй сеңгән дә көзләр кочагына,
Аерылам дими тиз генә.

Йолдыз ява, гүя өрәңгеләр
Зәңгәр күлгә йолдыз коялар.
Ә тал исә яфрак-балыкларын
Алтын-сары төскә буяган.

Күл өстендә әллә яфрак йөзә,
Әллә минем хисләр тирбәлә...
Күңелемдә җем-җем рәшә уйный,
Төсләр алып якын-тирәдән.

Исем китеп, сине тыңлап барам,
Шагыйрьнеке, ахры, йөрәгең:
«Бу көзге көн, якын дустым, — дисең, —
Истәлеккә сиңа бүләгем...»

Зәңгәр күлдән чыккан чишмәләрнең
Учыбызга алып салкынын,
Сүндермәкче булдык инде әллә
Йөзебезгә капкан ялкынны.

Сабыйларча беркатлы мин бүген,
Үз-үземнән хәтта оялам.
Әйтерсең лә чишмә суы түгел,
Шәраб эчкән сыман тоелам.

Хәмер эчми башлар әйләнерлек
Мизгел бүләк иттең, мең рәхмәт.
Сулап туймас көзге бәлзәм-һава
Янган йөрәкләргә, һай, рәхәт!
Үзе шатлык, үзе сагыш җанда!
Җәйләр сула, көзләр чәчәктә.
Тәүге тапкыр көзгә гашыйк булдым,

Хәйран гомер җирдә яшәп тә.

«Яшәү — бәхет!» диеп, бар дөньяга
Килгән иде сөрән саласым,
Баеп барган кояш куркыр диеп,
Әйттем бары тәһлил-догасын.

Югарыда кошлар аваз салды,
Ерак юлга дәшеп бер-берсен...
Саубуллашу җырында да хәтта
Шатлык ишетелә әйтерсең!

Әйтерсең лә Яшьлек үзе кайткан
Кунак булып күзләр иленә.
Озатып калды безне Зәңгәр күлдә,
Чиккән шәлен салып иңенә.

*3 октябрь, 1999*

## Газаплама

Сөюем хак, тик гомерлек түгел:
Ул нәкъ безгә кирәк кадәрле.
Китәм дисәң әгәр, хәерле юл,
Тоткарламам сине, кадерлем.

Хисем кайнар, тик чамалы гына:
Сиңа, миңа гына җитәрлек.
Сөю юлларымның чакрымнары
Икәү җитәкләшеп үтәрлек.

Ят тоелсам, сиздер шул мизгелдә —
Сабырлыкның миндә юк чиге...
Сөяр булсаң, бүтән газаплама —
Күңелемнең сиңа юк биге.

*1999*

## Мин, чыннан да, сөя идем

Ни булды дип уйлап йөрмә,
Миңа берүк рәнҗи күрмә.
Ни булса да булган инде —
Онытырга тырыш мине.

Мин, чыннан да, сөя идем,
Бу — гомерлек, дия идем.
Бар да бетте, үтте-китте,
Хушлашырга вакыт җитте.

Тормыш матур, тормыш гаҗәп,
Сукты бары безнең сәгать.
Борчылма син, иртәгә көн
Бүгенгедән булыр әйбәт.
Соң мәртәбә йолдыз саныйк,
Дуслар гына булып калыйк.
Без сайлаган йолдыз сүнде —
Язмыш белән килешик инде.

*1999*

## Йөрәгеңне куй син йөрәгемә

Йөрәгеңне куй син йөрәгемә,
Оныт «сагыш» дигән сүзнең барын.
Кушылсыннар уйлар, тәннәр, җаннар —
Оныттырыйм әле дөньяларың.

Йөрәгеңне куй син йөрәгемә —
Сусаганбыз назга син дә, мин дә.
Башкаларга җанда урын нигә?
Бәхетле дә бүген икәү, тиң дә.

Йөрәгеңне куй син йөрәгемә —
Озак тормас бәхет, үтәр-китәр...
Соңгы кат күк татыйк сөю тәмен,
Үкенергә... калган гомер җитәр.

*2000*

## Мәхәббәт бишеге

Сайлап алып матур төсләр
Хыялым түрләреннән,
Үрим әле гүзәл бишек
Сөюем гөлләреннән.

Тирбәлербез икәү бергә
Мәхәббәт бишегендә.
Мине сөю, бары сөю
Яшәтә яшьлегемдә.

Бәйләм-бәйләм гөлләр китер,
Үрелсен хисләребез,
Аллы-гөлле хыялларга
Күмелсен кичләребез.

Берәүгә дә бирмәм сине —
Тапмадым югалтырга.
Рөхсәт итмәм икәү үргән
Хисләрне чуалтырга.

*2000*

## Дускаем-сердәшем

Безнең әле, яшәү кадерен белеп,
Канатланып йөрер чагыбыз.
Яшьлек килә, юл бирегез диеп,
Утка-суга керер чагыбыз.

Бигрәк чая кызлар икән болар,
Яшен уты кебек дисеннәр,
Дускаем-сердәшем!

Югалтулар килер, зур табышлар —
Әзер булып торыйк барысына.
Беребез — апа, беребез сеңел булыйк,

Баскан чакта сынау каршына.

Бигрәк тату кызлар икән болар,
Бертуганнар кебек дисеннәр,
Дускаем-сердәшем!

Беребез — ал, беребез гөл булыйк,
Пар чәчкәсе язгы болынның.
Дәртле көе, серле моңы булыйк
Кабатланмас яшьлек җырының.

Бигрәк матур кызлар икән болар,
Язгы гөлләр кебек дисеннәр,
Дускаем-сердәшем!

*2001*

## Ышанам

Тәрәзәгә карап уйга талам:
Урамнарда салкын кыш һаман.
Апрель керми карлар эреми, дисез,
Озакламас язлар, ышанам.

Бу табигать үзе бер могҗиза:
Быел көзләр җәйгә охшаган.
Җәй дә уза, гомерләр дә, дисез,
Минем йөрәк әле яшь һаман.

Пар сыерчык бала чыгарсын дип
Элгән ояларым бушаган...
Вакыт әрәм итмә, көтмә, дисез,
Килер сөю, килер, ышанам.

*2002*

## Моңлану

Бер яшь егет бигрәк, ай, моңлана,
Гитарасын алып кулына.
Йөрәк серен аңа ача кебек,
Сак-сак кына чиртеп кылына.

Моңы садә, көе шундый дәртле,
Яшь күңеленә берәү кергәнме?
Дөньяларын шулай оныттырып,
Әллә тәүге сөю килгәнме?

Ишетми дә мине ул, күрми дә,
Уйларына чумган уралып.
Бүлдерүдән куркып сөю җырын,
Мин тыңладым аны тын калып.

Ярты юлда җырың өзелмәсен,
Хыял канатларың сынмасын.
Саф күңлеңдә туган тәүге хиснең
Гомерләре кыска булмасын.

Бер яшь егет бигрәк, ай, моңлана,
Гитарасын алып кулына.
Гитарада түгел, уйный гүя
Күңелләрнең чиртеп кылына.

*2003*

## Китү

Китәм инде. Телисеңме-юкмы...
Күз яшьләре, зинһар, кирәкми.
Буш биштәрем асып чыгып китәм,
Учларыма кысып йөрәкне.

Озатырга чыкма, монысы артык —
Әйтер сүзләр бар да әйтелгән.
Яхшысы да узган, яманы да,
Сабыр йомгаклары сүтелгән.

Шөбһәләнмә, ачу төяп китмим,
Андый авыр йөкне алалмыйм.
Исемем дәшсәң, бәлки, борылырмын,
Тик яныңда бүтән калалмыйм.

Гафу итәм, бәхет теләп китәм...
Җылы эзләремә кар ятар.
Минем сөю булып кояш баер,
Алсуланып көн дә таң атар.

Биштәрем буш... Дүрт ягым да кыйбла.

*2004*

## Гөлбадран

Юл буенда үскән гөлбадраннар
Ямьле җәйнең җыйган җылысын.
Мин дә синнән җылы караш көтәм,
Мәхәббәтнең көтәм олысын.

Тәлгәш-тәлгәш сары гөлбадранга
Тып-тып тама кайнар яшьләрем.
Тәлгәш-тәлгәш сары сагыш йотып,
Үз-үземне алдап яшәдем.

Юл буенда үскән гөлбадранның
Башкайлары калды иелеп.
Гомер итеп була башны иеп,
Яшәп була сөеп-сөелеп.

Юл буенда үскән гөлбадранның
Төймәләрен җыйдым дәвага,
Әчеләре шифа булмасмы дип
Җанымдагы тынмас ярага.

*2004*

## Аңлашмыйча аерылыштык

Син дә парлы, мин дә парлы.
Матур гына гөрли тормыш.
Ник соң моңлы минем җырлар,
Синең йөздә нигә сагыш?

Аңлашмыйча аерылыштык,
Араларда — дистә еллар.

Үпкә саклап яшәү авыр:
Бер очрашсын иде юллар.

Бәгырьләрдән өзелеп төшкән
Багалмалар бигрәк татлы.
Исемеңне йөртә улым,
Синең кызың минем атлы.

Аккан сулар кире кайтмас,
Ерак калды инде яшьлек.
Мин үземне гафу иттем,
Соң димәсәң, бәхилләшик.

*2004*

## Ярый син бар

Иелдем гөл сабагыдай,
Хәлләр шәптән түгел әле.
Мин дигәнчә бармый тормыш,
Күңелемнең төшкән мәле.

Берьялгызым нишләр идем,
Ничек әле килә белдең?
Юатырлык сүзләр таптың:
«Кайгы түгел кайгың», — дидең.

Күкнең җиде катларында
Хыяллардан сарай кордым.
Куанычтан шашуымны
Бераз дәшми карап тордың.

Берьялгызым нишләр идем,
Ничек әле килә белдең?
«Мондый гына шатлыклардан
Башкаеңны җуйма», — дидең.

Кайгыны да, шатлыкны да
Ярый син бар бүлешергә.
Бер көн сине күрми торсам,
Сәбәп эзлим күрешергә.

Берьялгызым нишләр идем,
Ничек әле үзең килдең?
Синсез яши алмавымны
Каян белдең, каян белдең?

*2005*

## Кушылыйк куш каеннардай

Мин бит сине үзем теләп
Ходайдан сорап алдым.
Табуын таптым да, никтер
Сөюдән куркып калдым.
Алып кит мине, урлап кит,
Бернигә дә карама.

Үрмә гөлдәй җанга сарган
Сагышлардан арала.

Дөньям нурларга күмелде,
Син үпкәч күзләремнән.
Күкләрдән көткән бәхетне
Таптым Җир йөзләреннән.
Карашларың — төпсез упкын,
Ә хисләрең — өермә.
Кушылыйк куш каеннардай,
Аерылмаска гомергә.

Йөрәгеңдә урын тапсаң,
Синеке генә булам.
Теләсәң, беркем белмәгән
Яшерен сер булып калам.
Тик синең өчен сакладым
Саф хисләремне, иркәм.
Әйдә, дисәң, синең белән
Җир читенә дә китәм.

*2005*

* * *

Күпме сүз сөйләнде, вәгъдәләр эчелде...
Сәгатьнең телләре йөгерде ашыгып.
Сулышың җиленнән, сискәнеп, шәм сүнде,
Яраттың син мине, шашынып-шашынып.

Күпме сүз әйтелде. Әйтелде — онытылды...
Нигә соң бу вакыт борылмый кирегә?
Үткәнгә — салават. Үпкәм юк бөртек тә,
Тик өмет өзәргә ашыкмыйм әлегә.

Ни бәхет! Мин сөям. Мин татлы газапта...
Өр-яңа сагышлы җыр туды күңелдә.
Сәгатьнең герләре учыма баш салды.
Туктаттым вакытны...
Бәхетле көнемдә.

*25 июль, 2005*

* * *

Миңа сусап баккан карашыңда
Яшеренгән булса явызлык,
Куенымда сине назлаганнан
Хәерлерәк миңа ялгызлык.

Тугры калырсыңмы иртәгә дә
Антлар эчеп әйткән вәгъдәңә?
Саф ниятләр белән орындыңмы
Сиңа мәхбүс булган гәүдәмә?

Тел очыңда былбыл сайратуың
Барыр микән, белмим, озакка?
Мине шашып үпкән иреннәрең
Бикли алырсыңмы йозакка?

Китмәссеңме минем бәгыремне

Сәмум җиле кебек көйдереп?
Юләрдер син, димә, юләр түгел,
Сөям бары шашып-тилереп.

*25 июль, 2005*

## Ышандыр

Аның эзе калган сукмаклардан
Дәшмә мине сөю иленә.
Алып кермә аны коендырган,
Шашындырган бәхет күленә.

Чатнап ярылса да иреннәрем,
Ул татыган назны теләмим...
Мин яратам бары башкачарак, —
Үткәннәрдән сине көнләмим!

Телисеңме, оныттырам аны?
Җырга төрәм моңлы җаныңны?
Бәхеткәйнең ал нурына манам
Көтеп алган һәрбер таңыңны?

Гафу ит тә аның хыянәтен,
Яши башла, әйдә, яңадан.
Яшәреп кит, сафланып кал әле
Яңа туган кебек анадан.

Дәш син мине бүтән бер дөньяга —
Дәш ихластан, чакыр алдаусыз,
Һәм ышандыр яшәп булганлыкка
Хыянәтсез, рия-ялгансыз...

*2005*

## Ут һәм су

Казансу буйлары ком гына,
Дулкын кага ярга тын гына.
Югалтудан куркам эзләрең —
Мин бит сине озак эзләдем.

Йөрәгеңә дәва иттеңме
Казансуның салкын суларын?
Колач салып ялгыз йөзгәндә,
Талмадымы, бәгърем, кулларың?

Мин дә керим әле яныңа,
Иш булмаммы моңлы җаныңа?
Аңлагандай минем уйларым,
Каршы алдың сузып кулларың.

Сыендым мин синең кочакка,
Утлар капты җанга шул чакта.
Дөнья тоташ ут һәм су гына —
Яратам мин сине — шул гына.

*6 октябрь, 2005*

## Саумы, Яшьлек!

Саумы, Яшьлек!
Саф-самими җаным
Синдә яши, яши Сөю көтеп.
Танымаган булып йөз чөермә,
Карамале миңа чит-ят итеп.

Минем әле синнән киткәнем юк,
Үз-үземне эзләп йөрим һаман.
Гомер кичәм: тәүге сөю җырым
Еллар тозагында өзелеп калган.

Танымассың да шул: йөзем инде
Сагышлардан шактый сулып бара.
Карашларым шул ук, шул ук ласа —
Яле, күзләремә минем кара.

Аларда бит шул ук ихласлыгым,
Күңелемнең якты балкышлары.
Яшьлек язларымның яшькелтлеге,
Садә хисләремнең ак кышлары...

Назга сусау да бар, сагаю да
Нәүмизләнеп калган карашымда.
Тыңламыйсың, борылып карамыйча,
Мине ташлап китеп барасың ла?!

«Хуш, Яшьлегем!» генә дия алдым,
Сузган куллар калды күтәрелеп.
Йә Илаһым, бирче аек акыл,
Калган гомерләрне үткәрерлек!

Шулчак кемдер кайнар учын салды
Күккә ашкан канат-кулларыма.
Мең рәхмәтле Аллам, мине ишетеп,
Сөю үзе чыккан юлларыма.

*10 октябрь, 2005*

## Үзем булып калыймчы!

Көтмә миннән сабырлыклар,
Юашлык көтмә, яме?
Холкыңа күнә алмыйм, дип,
Гаҗизләр итмә, яме?

Сиңа карамасын дисәң,
Күзләрем капла, әйдә.
Сине назламасын дисәң,
Мә, кулларымны бәйлә.

Матур сүзләр әйткән чакта,
Тыңлама, сүзем бүлдер.
Йә, булмаса, барысына да
Миннән алдарак өлгер:

Күрешүгә, кочаклап ал —
Күндәм генә торырмын.
Суырып үп иренемнән —
Телсез-сүзсез калырмын.

Шалтырат үзең беренче,
Зарыктырып бетермә.
Яратам, дип, үзәккә үт —
Көнләшерлек иттермә.

Булды, җитәр, күп сөйләндем,
Кил, иркәләп алыймчы...
Яратыйм, назлыйм, кадерлим —
Үзем булып калыймчы!

*10 октябрь, 2005*

## Җаныма нидер җитми

Очрашу өчен чакыру көтәсең,
«Кит» дию белән борылып китәсең.
Йөрәгем давыл теләгән чакта
Тынычланырга киңәш итәсең.

Язмышым миңа матур фал ача,
Күңел канатым күкләрне коча.
«Сабыр була бел, тукта» дисең дә,
Бар хыялларым җилләргә оча.

«Мин сөям икән — гомергә» дисең,
Һаман сөйлисең, тыңлыйм димисең.
Бәлки, ярата беләсеңдер дә,
Тик яраттыра гына белмисең.

Юк!
Биргән суларың сусауны басмый!
Шаян сүзләрең күңелемне ачмый!
«Бәгырем» диюең бәгырьгә үтми,
Җаныма нидер җитми.

*15 октябрь, 2005*

## Бердәнберемә

Нигә юкка шикләнәсең,
Нигә юкка сыныйсың?
Ятларга яр булырсың, дип,
Ник аерылу юрыйсың?

Синеке мин, тик синеке!
Күрмисеңмени үзең?
Газаплама, газапланма —
Оныт «хыянәт» сүзен.

Ышанырлык та түгел шул
Артык кайнар хисләрем.
Сөюемнән йөрәгемә
Утлар капса, нишләрмен?

Үзең дә «бердәнберем» дип
Әйтче күземә карап.
Ятка күз салмаслык итеп,
Миннән дә ныграк ярат!

*17 октябрь, 2005*

## Безнең сөю

Кайчакларда бер дә юкка гына
Куйсаң хаксыз сүзләр әйткәләп,
Мин түгел ул, шулай, сулык-сулык,
Безнең сөю елый үпкәләп.

Көлүеңдә, атлап йөрүеңдә
Разыйлыгың китсә чагылып,
Мин түгел ул, йөри яннарыңда
Безнең сөю, канат кагынып.

*30 ноябрь, 2005*

*** * ***

Бер-беребезне тагын үпкәләттек,
Соңгы чиккә барып җиттек бүген.
Түп-түгәрәк иде дөньялары —
Дөньяларның чите китек бүген.

Син — бер якка, мин икенче якка
Саубуллашмый гына киттек бүген.
Төне кара, йолдызлары сүнгән,
Аебызның чите китек бүген.

Нәүмизләнеп күзгә карап торган
Мәхәббәтне ятим иттек бүген.
Синең белән минем юләрлектән
Бәхетебезнең чите китек бүген.

*30 ноябрь, 2005*

## Соңгы бүләк

Өметемне өзеп сулган чакта,
Сынды дигәч сабыр канатым, —
Изге нурдай иңдең күңелемә:
Бер күрүгә сине яраттым.

Гөнаһларым өчен җәзамы син,
Соңгы бүләгеме язмышның?
Иртә килеп син ялгыштың микән,
Соңга калып минме ялгыштым?

Гомерем буе сине эзләдем, дип,
Күзләремә сөеп багасың.
Кулларымны кушып үбәсең дә
Татлы газапларга саласың.

Зәгъфрандай, әйдә, саргаешмыйк,
Сабырлыклар сорыйк иң элек.
Дөньялыкта безгә кавышу юк,
Кавыштырыр, бәлки, мәңгелек...

*2006*

## Мин синең өчен яратылганмын

Кул җылыларың йөрәкне эретә,

Җанны иркәли назлы көлүең.
Син минем өчен яратылгансың —
Миңа бик кирәк моны белүең.

Сине, җанымнан, тәнемнән өзеп,
Беркемгә килми, килми бирәсем.
Без сөю өчен яратылганбыз —
Монысын инде үзең беләсең.

Күрешүне гел кичектерсәң дә,
Әле килерсең, барыбер килерсең.
Мин синең өчең яратылганмын —
Әле аңларсың, әле белерсең.

*2006*

* * *

Әбелхәят чишмәсенең бер тамчысы
Әйтерсең кан тамырларын кузгатты ла,
«Син — бәхетем, син — язмышым» диюләрең
Яшәвемнең бар мәгънәсен үзгәртте лә.

Гозерхаһлы догаларым кабул булсын,
Озын гомер насыйп булсын бу гыйшкыма.
Сабыйларча ихлас җаным мең-мең разый —
Яшим әле, яшим әле дип ашкына.

*2006*

* * *

Сез кая илтәсез, юлларым?
Сез кая чабасыз, уйларым?
Мин беләм: ул көтә, бик көтә —
Менә шул йөрәкне җилкетә.

Китимме борылып кирегә,
Яшимме сабышып тилегә?
Сарылып ярымның муенына,
Керимме бәхетнең куенына?

Кайларга илтсә дә юлларым,
Гел аңа тоташа уйларым...
Акылым әйткәнне тыңладым,
Тик йөрәк кушканны сайладым:

Өзелә күрмәгез, юлларым!
Туктала күрмәгез, уйларым!
Мин беләм: ул көтә, бик көтә —
Шул мине бәхетле яшәтә!

*2006*

## Ник дәшәсең?

Нәни песи кебек иркәләнеп,
Куеныңа килә керәсем.
Назларыңда килә коенасым,
Уйларыңны килә беләсем.

«Йөрәгемдә синә урын түрдән,
Бердәнберем — син ул», — диясең;
Ләкин үзең, алларыңа алып,
Башка йомшаккайны сөясең.

Нәни песи кебек сырпаланам,
Яратыла беләм белүен;
Яннарымда ләкин башка берәү,
Шул берәүне сөйми көнләшем...

Кил, песием, диеп ник дәшәсең,
Куеныңда урын булмагач?..
Күк күкрәүдән, әйтче, нинди файда,
Коеп-коеп яңгыр яумагач?!

*2006*

## Агыла гомер, агыла

Хәбәрең көтә-көтә, сабырлар итә-итә,
Мизгелгә мизгел ялгана... вакытлар акрын үтә.

Агыла гомер, агыла,
Агылып аккан ком кебек —
Сагынганда-саргайганда
Сәгате дә көн кебек.

Сабырлар итә-итә, көткән минутлар җитә,
Мизгелгә мизгел ялгана... вакыт үтә дә китә.

Гомеркәйнең узулары
Дөрләп янган утка тиң.
Ике гашыйк кавышканда,
Сәгате минутка тиң.

*2006*

## Кичә һәм бүген

*(А.Кашинадан тәрҗемә)*

Бүген мин яз кебек гүзәлмен,
Бүген мин — бер көяз күбәләк.
Ә кичә башбирмәс зат идем,
Бер горур җан идем, ни гаҗәп!

Бүген бит барысы да үзгәрде,
Әйтерсең мин инде мин түгел!
Мин сиңа гашыйкмын — шул гына,
Һәм бүген кичәге көн түгел.

Самими күңелем — шау чәчәк,
Мин назлы, мин балкыйм, очынам!
Туасы көнемдә өмет бар —
Мин шуңа ихластан ышанам.

*12 апрель, 2006*

## Тормыш — сәхнә

*(А.Кашинадан тәрҗемә)*

Йә шатлыктан яңгыратып көләм,
Йә дөньяга сагыш таратам.
Йә яшәүдән кинәт җаным бизә,
Йә тормышны үлеп яратам.

Кирәк икән, мин беркатлы туташ,
Кирәк икән, булам горур кыз.
Шаярам һәм чаяланам кайчак,
Йә топ-модель булам, йә йолдыз.

Патшабикә иртән — илаһи зат,
Кичен хәлем Алла кулында.
Менә кош күк очам канатланып,
Йә елан мин дошман юлында.

Йөздә — битлек, ләкин йөзем җуймыйм,
Төш күргәндәй яшим өнемдә.
Бер хыялый иләс актриса мин,
Һәм урыным — сәхнә түрендә.

*12 апрель, 2006*

## Очрар әле

*(А.Кашинадан тәрҗемә)*

Барысы да сыйган күңелемдә
Артты җимерек дөньям хәрабәсе.
Миңа таныш түгел сукмаклардан
Дәшә һаман серле ут шәүләсе.

Басылды күк бәгырь әрнүләре,
Җан ярасы түгел инде киртә.
Үзем яккан ялгыз учак уты
Бу мосафир җанны кая илтә?

Кыйтгам эзлим шулай, абына-егыла,
Фани өметемә ябышып торам.
Юклык кичеп йөргән илгизәр мин,
Билгесезлек — минем туктар урын.

Гел эзләнәм, археолог сыман,
Җимерек хыялларым артта кала.
Очрар әле юлда тугры бер дус
Төзешергә яңа уртак кала.

*12 апрель, 2006*

## Хушлашу

Уй җитмәслек бөек хыял идең,
Буй җитмәслек биек кыя идең, —
«Сөям!» дигән кайнар сүзләремнән
Тезләндең дә кочтың тезләремнән.

Бу очрашу тәүге мәртәбә.
Бу очрашу соңгы мәртәбә.
Үзем теләп сине ятка бирәм —

Үкенүләр калсын иртәгә.

Минем сөюемне белмәс идең,
Чакырмасаң, мәңге килмәс идем.
Ләкин кабат күрешүне көтмә,
Көтмә мине, вакыт әрәм итмә.

Узган эшкә әйтик без салават,
Тәүбә иттем мин дә кабат-кабат...
Кичер безне, кичер, газиз Аллам!
Һәм синнән дә гафу сорап калам...

Бу очрашу тәүге мәртәбә.
Бу очрашу соңгы мәртәбә.
Бу кавышу түгел, бу — хушлашу,
Үкенүләр калсын иртәгә.

*2006*

## Сөйләшмик ярату турында

Сөйләшмик ярату турында,
Куыйк без сөюне йөрәктән.
Очрашу-кавышу көннәрен
Әйләнеп узыйк без ерактан.

Абына-сөртенә йөгермик
Телефон зыңлаган тавышка.
Төн буе шигырьләр укышмыйк,
Уздырмыйк вакытны без бушка...

Сүндерик йөрәкнең ялкынын,
Күмергә каласын уйлыйк та...
Тешлик без иренне нык итеп
«Сөям!» дип әйтәчәк минутта.

Көтмик без язмыштан могҗиза,
Сак булыйк хәвефтән-хәтәрдән...
Сөюдән гакылымны җуярмын,
Тик сине җуялмам хәтердән!

*2006*

*** * ***

Каләмемнең кипте карасы,
Сулык-сулык йөрәк ярасы...
Гамьсез күңел, синсез йөрәк белән
Ничек кенә яшәп карасы?

Каләмемнең алдым яңасын,
Догам япты йөрәк ярасын.
Аллаһыма сыенып үтмәк булдым
Фани белән бакый арасын.

*2006*

## Янартавым

Яңа тапкан утравым син —
Үзең ерак, үзең якын.
Утрау түгел, янартау син —

Тышың салкын, эчең ялкын.

Хәтта хыял үталмаслык
Нык киртәләр минем алда.
Очкын төшсә, «гөлт» итәрлек
Утлы күмер минем җанда.

Әй, янартау! Юллар табып,
Сиңа килдем, күрәсеңме?
Туңган йөрәк җылы сорый —
Бер уч җылы бирәсеңме?

Уй җитсә дә, буй җиталмый —
Үзең ерак, үзең якын.
Атылмаган янартау син —
Тышың салкын, эчең ялкын.

*16 февраль, 2007*

## Розалар

Ак розалар бүләк иттең миңа,
Күзләремә сөеп карадың.
«Ак розалар — сафлык билгесе» дип,
Ак бәхетләр миңа юрадың.

Кулларыңда — уттай гөлчәчәкләр,
Ялкынлысы ихлас сөюнең.
Кочак тулы кызыл розаларың —
«Мин яратам сине» диюең.

Сары роза сагыш алып килде,
Яшерен хиснең соңгы көннәрен.
Мәхәббәтең матур уен булган —
Алдамады сары гөлләрең.

Ал розалар — өмет билгеләре —
Серле балкып «мине ал» диләр.
Аңларсыңмы өзелеп көтүемне,
Бүләк итсәм әгәр ал гөлләр?!

*28 февраль, 2007*

## Тәүге ярым

Садә яшьлегемдә өзелеп сөйгән
Онытылмас тәүге ярым син.
Күңел түрләремдә саклап йөрткән
Үзем генә белгән җырым син.

Юлларыбыз безнең аерым-аерым
Менгән чакта гомер үренә.
Тик шулай да күрешәсе иде,
Сөйләшәсе иде бер генә.

Саф хисләргә күңелем сусаганда
Үкенүдән дәва тапмыйм мин.
Көч бирүче изге чишмәм итеп
Күңелемдә сине саклыйм мин.

Тәүге ярын, әйтче, кем сагынмый?
Сөю — иң-иң татлы хатирә.
Гүзәл яшьлегемнең үзе булып
Калдың, тәүге ярым, хәтердә.

*Гыйнвар, 2008*

## Хакыйкать

Гомер итеп булмый икән
Җанны икегә ярып...
Мин барыбер үткәннәргә
Җитә алмадым барып.

Берексә дә куш игездәй
Ялганы-чыны бергә,
Куш йөрәк белән тумаган
Бирәү дә әле Җиргә.

Мин кайда — бәхет тә шунда:
Яши-яши аңладым.
Төшкән җиремдә таш булыйм —
Бүгенгемне сайладым.

*12 март, 2008*

# Оч иреккә, җырым!

## Дәшмә миңа, соң инде...*

Кочагыңнан тартып алды
Каты куллы язмышым.
Ә мин юләр, ычкынмыйм дип,
Кулларыңа ябыштым.

Кулың салкын, карашың ят,
Күзләреңдә боз иде.
Назың күчкән башкаларга...
Тотма кулдан, соң, диден.

Башым иеп, ялгыз атлыйм,
Киселде өметләрем.
Төзәтик ялгышларны, дип
Дәшәреңне көтмәдем.

Бәгырем — таш, күземдә — яшь,
Миңа юлдаш моң инде.
Теләсәм дә кичерә алмыйм,
Дәшмә миңа, соң инде.

*1982*

## Ялгыз әнкәй*

Рәнҗетмикче әнкәйләрне.
Хат язганчы, кайтып килик.
Күчтәнәчләр юллаганчы,
Бер күрешеп, хәлен белик.

Кушымта:

Көннәр үткән, төннәр үткән.
Ни арада картлык җиткән.
Җилдәй искән гомеркәйне
Газиз әнкәй ялгыз кичкән.

Сагынулардан сыза-сыза,
Күңеле һаман безне көтә.
Тик капканы каерып ачып,
Җилләр генә узып китә.

Кушымта.

Кайтып киләм, башым иеп,
Бәхиллегең алыйм диеп,
Йа Ходаем, каршы алсын
Якты утың, җылы өең.

Кушымта.

*Март, 1992*

## Кура җиләк*

Кура җиләк пешкәндер, дип
Чакырдың урманнарга.
Күмелдек икәү кереп без
Ут янар кураларга.

Кушымта:

Коела инде куралар,
Җил үтте аралардан.
Ялгызым йөрим адашып
Куралы аланнарда.

Җем-җем яна кура җиләк,
Җыймыйча булмый түзеп,
Уч тутырып кура җиләк
Ашаттың миңа өзеп.

Кушымта.

Иң бәхетле чакларымны
Хыялда йөрим гизеп.
Кура җиләк кабат пешкән,
Тик кем ашатыр өзеп?

Кушымта.

*1994*

## Пар алма*

Алларыма килеп тезләндең син,
Кулларыңда иде пар алма.
Төшләремә кереп һәр көн шулай
Таң атуга китеп югалма.

Кушымта:

Өзелепләр төште пар алмакай,

Ятимләнеп калды алмагач.
Өзелә бит инде үзәккәем,
Ялгызлыктан дәва булмагач.

Пар алмадай идек, пар алмадай,
Үз күзләрем тиде, күрәсең.
Багалмадай, бигрәк матур булып
Төшләремә генә керәсең.

Кушымта.

Җанга ява бары салкын көзләр,
Бар төсләрне җирдә тигезләп.
Төшләремдә күргән пар алманы
Бакчаларда йөрим мин эзләп.

Кушымта.

*1995*

## Балачагыма кайтам*

Хыялымдай атка менеп,
Эх, бер чабасы иде.
Колындай балачагымны
Эзләп табасы иде.

Кушымта:
Төшләремә керә бары
Җилләрдәй җитез атым.
Муеннарына сарылып,
Сабый чагыма кайттым.

Атлар утлап йөри микән
Ялансу буйларында?
Төннәрен атлар саклыйм мин
Бары тик хыялымда.

Кушымта.

Колыннар чабып узадыр,
Туздырып тузаннарны.
Үтәдер бу гомеркәйләр,
Юксынып узганнарны.

Кушымта.

*1995*

## Моңаймагыз, шомыртларым*

Үткәннәрдән синең төсең булып,
Истәлеккә калды моң гына.
Без утырткан шомырт агачлары
Чайкалалар җилдә тын гына.

Кушымта:
Моңаймагыз әле, шомыртларым,
Сыгылмагыз сыкрап җилләрдә.
Күтәралмас әче хәсрәтләрем

Сездән башка сөйлим кемнәргә?

Язлар җиткәч, бер-берсенә сыенып,
Ак чәчәккә күмелә шомыртлар.
Син янымда чакны хәтерләтә
Үзәк өзгеч шушы вакытлар.

Кушымта.

Күзләремдә инде яшь кипкән,
Тик җан гына сыкрап гел елый.
Минем яшем булып, шыбырдап,
Җиргә кипкән шомырт коела.

Кушымта.

*1995*

## Әйтер сүзең әйтеп кал*

Агыйделдә ике сал:
Берсе — каен, берсе — тал.
*Татар халык җырыннан*

Агыйделкәй буйларында
Үсә кара карлыган.
Күптән инде көнелем сизә
Әйтер сүзең барлыгын.

Кушымта:
Агыйделдә ике сал:
Берсе — каен, берсе — тал...
Сагынганда үкенерсең —
Әйтер сүзең әйтеп кал.

Кара карлыганнар җыйдым,
Калдырмыйча вакларын.
Бер җылы сүз әйтер идең,
Күңелем китек чакларым.

Кушымта.

Җыйган карлыганнарымны
Ашарга өлгермәдең.
Син дәшмәгәч, мин дә түздем —
Серемне белдермәдем.

Кушымта.

*1995*

## Чишмәләрдә керләр чайкыйм*

Чишмәләрдә керләр чайкыйм,
Ай-һай салкын сулары.
Серем чишсәм, челтер чишмәм
Сагышымны юармы?

Кушымта:
Көянтәле пар чиләгем
Авыр шул иңнәремә.

Мөлдерәмә күңелемне
Бушатыйм кемгә генә?

Чишмәләрдә керләр чайкыйм,
Кулларым тала инде.
Салкын чишмә суларына
Яшьләрем тама инде.

Кушымта.

Чишмәләрдә керләр чайкыйм,
Кире кайтырсың кебек.
Кулың туңган, бир, җылытыйм,
Диеп әйтерсең кебек.

Кушымта.

*1996*

## Арчаларда калып булмады*

Арчаларга тимер юллар илтә,
Урамнары аның бормалы.
Кайларда сез, урамнарга сыймас,
Гөрләп үткән яшьлек елларым?

Кушымта:
Истә әле Арча урамнары,
Су буена төшкән сукмагы.
Үкенепләр үтә гомерләрем —
Арчаларда калып булмады.

Казансуда кызлар кер чайкамый,
Сулары сай хәзер Арчаның.
Тар басмада тәүге ярым калды,
Аның белән бергә яшь чагым.

Кушымта.

Сабантуйлар җитсә, Арчаларга
Әйләнә дә кайта юлларым.
Урамыңда мин тик кунак хәзер,
Читтә булгач эчәр суларым.

Кушымта.

*1996*

## Син — башканың бәхете*

Йөрәгемне учларыма
Йомарлап түзәм инде.
Уйларымны күзләремнән
Укыйсың, сизәм инде.

Кушымта:
Гафу үтенмә, кирәкми,
Син — башканың бәхете,
Кайларда йөрдең адашып,
Соңлаган мәхәббәтем?

Никадәрле күзләреңә
Карамаска тырышам.
Мине түгел, ташны эретер
Бер ялкынлы карашың.

Кушымта.

Теләсәң, шашкын хисләрне
Туктатып була, имеш.
Булдыралсаң, янмый кара,
Йөрәгеңдә ут килеш.

Кушымта.

*1996*

## Толымнарым*

Ай нурларын кушып тараганга,
Толымнарым булды микән озын...
Таңда чишмәләрдән су китергән
Авыл кызы бит мин, авыл кызы...

Кушымта:
Тибрәндереп толымнарым,
Суларга бара идем.
Мин бит туган авылымда
Бәхетле бала идем.

Толымнарым алгач кулларына,
Ап-ак булды кинәт әнкәм йөзе.
«Бәхетләрең киселә күрмәсен» дип,
Кабат-кабат дога кылды үзе.

Кушымта.

Толымнарым — әнкәй сандыгында,
Толымнардай сүтелеп гомер уза.
Бәхеткәйләр эзләп читтә йөргән
Авыл кызы бит мин, авыл кызы...

Кушымта.

*1996*

## Ялгыз учак

Ямьле язда әллә тугангамы,
Язлар килсә, яшьним, терелэм,
Өметемнең соңгы чаткысыннан
Дөрләп янган учак тергезәм.

Кушымта:
Учагымны читтән күзләп үтә
Күшеккәннәр, ялгыз-ярымнар.
Тик янымда күптән саклап торткан
Сиңа гына дигән урын бар.

Әллә инде «очрашырбыз» дигән

Уйларыңнан кире кайттыңмы?
Йә, булмаса, ялан кырга чыгып,
Берьялгызың учак яктыңмы?

Кушымта.

Көтә-көтә зар-интизар булсам,
Көтмәм бүтән, үзем барырмын.
Сүнеп барган ялгыз учагыңа
Утлы күмер илтеп салырмын.

Кушымта:

Ямьле язда әллә тугангамы —
Язлар килсә, яшьним, тереләм.
Өр-яңадан туган кебек булам —
Яфрак туган кебек бөредән.

*1996*

## Сары кашкарыйлар*

Өзгәләнеп көттем кабат күрешүне,
Килдең менә бүген яңадан.
Бүләк итеп биргән сары чәчәкләрең
Мин аерылу диеп аңладым.

Кушымта:

Кулларыңда сары, сары кашкарыйлар,
Ә мин көткән идем акларын.
Минем дә бит бүген, сары гөлләр кебек,
Сагышлардан сулган чакларым.

Нишләтергә белмим биргән чәчәкләрең,
Йөзләремә яуды сарысы.
Нинди генә дәва табыйм йөрәгемә,
Сулык-сулык килә ярасы.

Кушымта.

Өй түремә үзем кашкарыйлар чәчтем,
Кайнарлыгын кушып хисемнең.
Хак сөюем булып ап-ак чәчәк атсын
Гөлләр белән язган исемең.

Кушымта.

*5 ноябрь, 1996*

## Ана җыры*

Бәхеткәйләр сагындырып кына
Шакый диләр өйнең ишеген.
Белгән догам укып эчтән генә,
Өй түремә элдем бишегең.

Әй балам, багалмам,
Бәхетеңне бирсен бер Аллам.

Кайгы-хәсрәт рөхсәт сорап тормый
Үтә икән өйнең түренә.

Алларыма алып сине сөйсәм,
Ачы хәсрәтем дә сүрелә.

Тигез канат җылысына сыенып,
Насыйп булса иде яшәргә.
Соң сулышта, башкаеңнан сыйпап,
Риза-бәхил, диеп дәшәргә.

Әй балам, багалмам,
Тәүфыйгыңны бирсен бер Аллам.

*1996*

## Рәхмәт, Казаным*

Дәште мине шәһәр шау-шуы,
Төшләремә кергән матурлык.
Гүя тәлгәш-тәлгәш бәхетем
Ераклардан алды чакырып.

Кушымта:
Үз иттең син, рәхмәт, Казаным,
Мин кыюсыз авыл баласын.
Кем уйлаган, шулай яратып,
Гомерлеккә синдә каласым.

Туган нигез биргән канатлар
Синдә ныгып үсте тагын да.
Баштан сөеп гүя юаттың,
Сагынып күңел тулган чагында.

Кушымта.

Синдә таптым сөйгән ярымны,
Дуслар таптым гомер итәрлек.
Заманабыз язган язмышны
Алмаш-тилмәш бергә күтәрдек.

Кушымта.

*13 декабрь, 1996*

## Мәхәббәтле бул*

Язмыш йөген салып иңнәремә
Тормыш сикәлтәсен узганда,
Ерак юлдан кайтып керсәм арып,
Җан җылыңны берүк кызганма.

Кушымта:
Синең кулда минем язмышым,
Кичерә күр, булса ялгышым.
Кире какма, мәрхәмәтле бул,
Җан эрерлек мәхәббәтле бул.

Кайчакларда күңел — ирекле кош,
Дөньям онытып йөргән чагымда.
Алда оҗмах дәшеп торса торсын,
Сукмакларым илтсен яныңа.

Кушымта.

Күңелдәге бозны эретер өчен
Бер ягымлы, җылы сүз җитә.
Мәхәббәткә, сүнми янар өчен,
Аз да, күп тә түгел — Без җитә.

Кушымта.

*20 июнь, 1997*

## Мин ул, әни, синең яшь чагың*

Әнкәемнең ал күлмәген киеп,
Бөтереләм көзге каршында.
Нинди хатирәләр саклыйсың син?
Сер булмаса, сөйлә барсын да.

Кушымта:

Сабыем, дип, һаман эндәшсәң дә,
Үсте инде нәни кошчыгың.
Гомер уза, диеп уфтанмале,
Мин ул, әни, синең яшь чагың.

Бала итәкле алсу күлмәгеңне
Бәйрәмнәрдә алып кидеңме?
Талчыбыктай нәзек билләреңә
Ак алъяпкыч бәйләп йөрдеңме?

Кушымта.

Күлмәкләрнең киям затлыларын:
Йә кыскасын, яки озынын.
Тик әнкәмнең алсу күлмәгеннән
Урам әйләнергә кызыгам.

Кушымта.

*1997*

## Килә бүген ялгыз каласым*

Күлмәгемнең кидем яңасын,
Чәчләремне салдым таратып.
Яшь аралаш никтер елмаеп,
Әнкәй калды мине озатып.

Кушымта:

Әйләндек без кызу бию көенә,
Җем-җем утлар күзен кысып әйләнә.
Кичә тәмам. Дус кызымны
Син озата киттең өенә.

Төсле утлар сүнеп баралар,
Берәм-берәм парлар тарала.
Күз яшьләрем ничек яшерим?
Син борылып берүк карама.

Кушымта.

Күлмәгемнең кидем карасын.

Килә бүген ялгыз каласым.
Сорауларың калдыр иртәгә,
Минем хәлне, әнкәй, аңласаң.

Кушымта.

*1997*

## Оч иреккә, җырым!*

Җырым минем — иреннәрнең назы,
Сөйгәнемнең йөрәк тибеше,
Яшь кызларның Казан урамыннан
Дәртле басып атлап килеше.

Кушымта:
Моңлыларның кагыл җаннарына,
Нечкә күңелләрне назлап коч.
Тоткын булып берүк яши күрмә,
Оч иреккә, җырым, әйдә, оч!

Сабый, тугач, дәшә бар дөньяга,
Изге моң ул аның тавышы.
Җырларымда — яшь ананың бәхете,
Ялгыз калганнарның сагышы.

Кушымта.

Җан авазым туа җырлар булып,
Моңсыз калсам, белмим, нишләрмен.
Сүзләр белән әйтә алмаганга,
Җырга салам яшерен хисләрем.

Кушымта.

*4 сентябрь, 1998*

## Син сөюдән чибәр*

Сөюемнән мин бер чибәр идем...
*Э.Шәрифуллина*

Бәхет ачкычлары таптыңмы,
Әллә оҗмах кошы тоттыңмы?
Йә, булмаса, әкият егете
Юлларыңа үзе чыктымы?

Кушымта:
Йолдызлар күп, бик күп, санасаң,
Матурлар күп, бик күп, сайласаң...
Син сөюдән чибәр, күз тияр,
Йөзләреңә тутырып карасам.

Тәгәрәсен гомер йомгагың,
Сүтелсеннәр айлар-елларың.
Сөю патша булган илләргә
Алып барсын сине юлларың.

Кушымта.

Юлдаш булып сиңа иң элек
Янәшәңнән барсын Изгелек.
Йөзләреңә чыккан бәхетең
Була күрсен берүк гомерлек.

Кушымта.

*23 февраль, 1998*

## Телефон дәшми*

Яшәвем газапка әйләнде,
Ник кенә янымнан җибәрдем?
Үпкәләп киттең дә син миңа,
Юк хәзер бернинди хәбәрең.

Телефон яныннан китмичә,
Сәгатьләр буена утырам.
Бу үле тынлыкка җан керсен,
Йә инде, телефон, шалтыра!

Ничәнче тапкырлар кар күмде
Эземне тәрәзәң төбендә.
Урамда караңгы төн инде,
Утыңны сүндердең бүлмәңдә.

Бәгырең таш булса, син йокла,
Мин төнне уздырам йокысыз.
Иртәгә бүлмәңдә көнозын
Телефон шалтырар туктаусыз.

Телефон дәшми, ул синең яклы.
Кем соң гаепле, кайсыбыз хаклы?

*25 февраль, 1998*

## Йөрәгемә карый күзләрең

Болытлы көнемә нур иңде,
Бар дөньям яктырды, күр инде.
Син мине сүзсез дә аңладың —
«Дус булыйк» дидең дә кул бирдең.

Кушымта:
Йөрәгемә карый күзләрең,
Бигрәк матурлар шул үзләре.
Күз карашыңнан да ягымлырак
«Без бит икәү» дигән сүзләрең.

Иркә син кайчакта аз гына,
Елмайсаң, сирпелә наз гына.
Ягымлы тавышың күңелгә
Әйтерсең җыр булып языла.

Кушымта.

Мин синең барлыгың белмәдем,
Очрарсың дип көтеп йөрмәдем.
Бар назын тик сиңа саклаган,
Кайлардан белгәндер йөрәгем?

Кушымта.

*2 март, 1998*

## Адаштык Мәхәббәт илендә*

Кояшка үрелә бар гөлләр,
Җылыга тартыла күңелләр.
Нигәдер юл тапмыйм мин генә
Үтәргә йөрәгең түренә.

Кушымта:

Калдырдың да киттең
Җиде юл чатында,
Эзләп тап син мине,
Яратсаң, диден дә.
Уңнарда — кыямәт,
Сулларда — хыянәт...
Адаштык Мәхәббәт илендә.

Сынауның авырын калдырдың:
Ялгызым көйдердең, яндырдың.
Кыя таш түгел бит бәгырьләр,
Аңла син: бер генә гомерләр.

Кушымта.

Җиде ай, җиде ел барсам да,
Зилзилә эчендә калсам да,
Кирегә борылып китмәмен —
Табармын күңелең бикләрен.

Кушымта.

*Май, 1998*

## Күрше кызы*

Кем уйлаган йөрәгемнең
Түренә үтәрсең дип,
Җәйге озын төннәремне
Йокысыз итәрсең дип.

Кушымта:

Күрше кызы, чибәрем,
Син дип тибә йөрәгем.
Күптән күзем төшкән сиңа,
Белми генә йөргәнмен.

Ялантәпи чабып йөргән
Балачак үткән икән.
Дөрли-дөрли сөюләрдә
Янар чак җиткән икән.

Кушымта.

Бүген кичен, сине дәшеп,
Тәрәзәң чиртәм әле.
Белми йөрмә сөюемне —
Яшермим, әйтәм әле.

Кушымта.

*1998*

## Тылсымлы Мәхәббәт*

Талпына, әйтерсең күбәләк,
Бу күңел, һай, бигрәк җилбәзәк.
Дөньясы җәннәт кук, болытсыз зәңгәр күк —
Нишләттең син мине, Мәхәббәт.

Кушымта:
Уйладым, уйладым... Сине генә уйладым...
Очратсам да, сине күреп
Туяр кебек булмадым...
Тынычлыгым урладың.

Сүз бирдем үземә кабаттан:
Уйламам, сагынмам, яратмам!
Ни генә итсәм дә, син генә исемдә,
Йокысыз үтә төн, ата таң.

Кушымта.

Җуйдым мин көчне дә, башны да
Тылсымлы Мәхәббәт каршында.
Бар сүзем шул гына: минеке бул гына,
Калганы безнеке барсы да.

Кушымта.

*1998*

## Алсу гөлем*

Күңелләрем — ярсу диңгез,
Йөрәк-утрау ятим синсез.
Чәчәк атмый, бөредә гел
Шул утрауда серле бер гөл.

Назлар алсын күзләреңнән,
Җылы алсын сүзләреңнән.
Гомерлек яр булсаң, иркәм,
Шул чәчәкне бүләк итәм.

Бар дөньяны нурга күмеп,
Рәшә сыман җем-җем көлеп,
Көтмәгәндә, таңда бүген,
Чәчкә атты алсу гөлем.

Чит-ят куллар сузылмасын,
Яман күздән ул сулмасын.
Җандай газиз күреп кенә,
Сакла назга төреп кенә —
Сөю гөлем бүләк итәм.

*1998*

## Кояшлы гомер*

Алмашынучан болытлы һава:
Йә кояш чыга, йә яңгыр ява.
Чалт аяз көнне яшен суккандай,
Утлы сүзеңнән йөрәгем яна.

Кушымта:
Кояшлы булыр, диден,
Һәрвакыт тормыш күгең.
Нигә соң күзгә болыттай
Мөлдерәп тулды күңелем?

Төньяктан исә әче салкын җил,
Бер ярсып куя, бер тына күңел.
Бер-берсен саклап җилдән-яңгырдан
Парлашып үткән, юк, ул без түгел.

Кушымта.

Кояшлы яңгыр, яусаң яу чынлап,
Йә күк күкрәтеп, йә бер давыллап.
Үтәлми калган вәгъдәләр кебек,
Торма гел көлеп, җанны яралап.

Кушымта.

*29 июль, 1998*

## Унҗиде яшь*

Мәктәп юлларында танышып,
Сөю тулы хатлар алышып,
Балачактан бик тиз киттек без,
Сиздерми дә үсеп җиттек без.

Кушымта:
Унҗиде! Тик унҗиде яшь!
Яшь әле, без әле бик яшь.
Мең төрле тормыш юллары —
Сөю илләренә мине дәш.

Канатлана күңел, ашкына,
Җанга сыймый хисләр ташкыны.
Безгә яшьлек үзе гашыйк бит,
Зур булырга, әйдә, ашыкмыйк.

Кушымта.

Дөрләп янсын сөю-учаклар,
Кире кайтмас безнең бу чаклар.
Бик күбәүләр бездән көнлидер,
Тик яшәрү серен белмидер.

Кушымта.

*10 декабрь, 1998*

## Әйдә, китик ерак-еракка...*

Борчу-хәсрәт өскә өелә,
Мәшәкатьләр тула өемә.

Дөнья гизүләре рәхәттер,
Кайда без юк, шунда бәхеттер.

Кушымта:
Кайгыларны онытырга телим,
Җитәкләшеп икәү — син дә мин —
Китик, әйдә, ерак-еракка —
Беркем аяк басмаган якка.

Җитәр диеп болай яшәргә,
Чыгып китик ерак сәфәргә.
Бер сәгатькә, айга, бер елга,
Буйсыныйк та юләр хыялга.

Кушымта.

Күрәчәкне урап узарбыз,
Гүзәл утрау эзләп табарбыз.
Бәлки, вакыт арттан җиталмас,
Бәлки, язмыш куып тоталмас.

Кушымта.

*1999*

## Әнкәем-сердәшемә

Сабый чактагыдай, иркәләнеп,
Алларыңа башым салыймчы?
Үзем күптән әни булсам да мин,
Нәни кызың булып калыймчы?

Чәчләремнән сыйпа әле, әнкәй,
Тойыйм кулларыңның җылысын.
Изге йөрәгеңә сыйдыргансың
Мәхәббәтнең иң-иң олысын.

Күңел кошым көн-төн сайраса да,
Син һәрвакыт әзер тыңларга.
Җанымдагы телсез сагышларым
Ярый син бар сүзсез аңларга.

Дустым да син, әнкәй, киңәшчем дә,
Бер серләшик таңга кадәрле.
Иң бәхетле шушы көннәремнең
Минуты да миңа кадерле.

*1999*

## Әниемнең туган көне*

Шатлыкларың торган онытылып,
Борчуларың булган җитәрлек.
Шуңа бәйрәмнәрең җибәргәнсең
Тыйнак кына итеп үткәреп.

Кушымта:
Әниемнең туган көне бүген.
Ярар инде, әни, елама.
Онытмадым, ничек итеп онытыйм.

Йә, бер елмай, авыр сулама.

Каушап калган нурлы йөзләреңә
Ак яулыгың бигрәк килешә.
Борчылмале, син һәрвакыт матур —
Гади күлмәк кигән килеш тә.

Кушымта.

Күңелемә сыймый куанычым,
Синең шатлык зуррак аннан да.
Җанымдагы җылы кояш булып,
Яшә, әни, шулай һаман да.

Кушымта.

*1999*

## Син — матур җырым*

Сиңа багышлап шигырьләр яздым,
Сиңа атап җырлар җырладым,
Сиңа тәүге кат «яратам» дидем —
Син бит бәхетем идең.

Кушымта:
Төшемдә, өнемдә —
Күңелемнең түрендә
Иң матур җыр булып
Яшисең син бүген дә.

Безгә тидеме ятларның күзе,
Безгә язмыш шулай язганмы,
Безгә насыйп яр хәзер бүтәннәр —
Тик онытылмый үткәннәр.

Кушымта.

Сиңа багышлап шигырьләр язам,
Сиңа атап җырлар җырлыйм мин,
Сиңа җырымда «яратам» диям —
Сине җырымда сөям.

Кушымта.

*1999*

## Безнең сөю*

Кемне назлый бүген татлы сүзең,
Кемгә сөеп карый шаян күзең?
Кайнар иреннәрең төннәреңдә
Гөлләр тезә кемнең йөзләренә?

Кушымта:
Бик бәхетле кебек яшәсәң дә,
Хәбәр биргәч, каршы дәшмәсәң дә,
«Оныттым» дип әйтү генә җиңел —
Безнең сөю онытырлык түгел.

Берни әйтми сиңа минем исем,
Минем барлыгымны син белмисең.
Син идеңме, әллә түгел микән
Миңа алтын таулар вәгъдә иткән?

Кушымта.

Мин яратам сине урлап кына,
Яшерен янып, яшерен уйлап кына.
Көнләшмәсен, әйдә, сөймәгәннәр,
Җирдә Сөю барын белмәгәннәр.

Кушымта.

*Июнь, 1999*

## Ни булды сиңа?*

Куеныңда йөрткән агулы хәнҗәрне
Бәгырьгә кадап киттең...
Синең күңелең бушап калгандыр,
Мине хәсрәтле иттең.

Кушымта:
Ни булды сиңа, ни булды —
Аңлатып бирсәң иде.
Сулкылдап елый йөрәгем —
Үтәли күрсәң иде.

Син мине, алай сабыр дигәч тә,
Сынама утка салып.
Сабырның соңгы кыллары сынар,
Сагыш утында калып.

Кушымта.

Туры сүз анысы яра ташны да,
Тик дәшми калу — алтын.
Көенер чакта сөелер мәлләрне
Тоттың да утка ктың.

Кушымта.

*1999*

## Җавапсыз сөю*

Мин яраттым сине. Сөюемне
Дулкын итеп тездем суларга.
Диңгез миңа тозлы яшьләр бирде
Сине сагынганда еларга.

Мин яраттым сине. Сөюемне,
Канат куеп, күккә күтәрдем.
Җаннарыма койды бозлы яңгыр,
Төннәремне ялгыз үткәрдем.

Мин яраттым сине. Сөюемне
Кабул итеп кенә алмадың.
Дәрьяларга сыймас хисләремне

Бер шаяру диеп аңладың.

Күк күкрәсен, яшен яшьнәсен!
Тик «яратмыйм» диеп дәшмә син.
Ятим сөю минем йөрәгемдә
Бер җылы сүз көтеп яшәсен.

*1999*

## Әткәй-әнкәй — пар канатым*

Язмыш йөген салып иңнәремә,
Үткән чакта тормыш юлларын,
Җан сөенә, җиңеләя адым,
Белеп янәшәдә сез барын.

Кушымта:
Әткәй-әнкәй — минем пар канатым,
Сез булганга, дөньям түгәрәк.
Иңне иңгә, җанны җанга куеп,
Яшик әле, яшик бергәләп.

Акыллы сүз, алтын киңәш белән
Авыр чакта ярдәм итәсез.
Адашканда, ак юл күрсәтүче
Күңел күзе ул сез икәнсез.

Кушымта.

Сезгә саулык телим һәр догамда,
Тигез бәхет телим һәрвакыт.
Мең рәхмәтләр әйтеп чын йөрәктән,
Карыйм сезгә сөеп, яратып.

Кушымта.

*2000*

## Дуслар кирәк һәрвакыт*

Якын дуслар булу аз, димә,
Җан дуслар ул үзе хәзинә.
Дөньяларның малы — бер көнлек,
Саклап тотсаң, дуслык — гомерлек.

Кушымта:
Яшерен серләремне чишәргә,
Кайгы килсә, уртак итәргә,
Үпкәләшер өчен, яратып,
Җан дусларым кирәк һәрвакыт.

Чит илләрдән алып кайтылмый,
Бизмәннәрдә үлчәп сатылмый.
Чын дуслыкның хакы югары —
Озын-озак гомер юллары.

Кушымта.

Якын дуслар — ярты бәхет ул,
Дуслар өе — алтын тәхет ул.
Якын булсын ерак юлыбыз,

Уртак булсын һәрчак җырыбыз.

Кушымта.

*2000*

## Яшьлегемә кире кайталмыйм*

Дугаларга чиккән сөлге бәйләп,
Моңлы кыңгыраулар чыңлатып,
«Авыл көе»н җырлап чыгып киттем,
Унсигезем калды озатып.

Кушымта:
«Туп-туп» иткән тояк тавышымы,
Йөрәк тибешеме — әйталмыйм...
Талпынса да күңел, ашкынса да йөрәк,
Яшьлегемә кире кайталмыйм.

Йөгән кидерелгән ярсу җанны
Җибәрәсе иде тугарып.
Ат саклаган төнге болыннарга
Килдем, ахры, шактый соңарып.

Кушымта.

Гармунымны алып җырлап карыйм,
Моң да башка, көй дә ят бүген.
Алмачуарымның күзләредәй,
Күңел мөлдерәмә чак бүген.

Кушымта.

*2000*

## Ашытбаш кызлары*

Авылыма алып кайта
Мине урман юллары.
Җырлый-җырлый җиләк җыя
Ашытбашның кызлары.
Әй сез, кызлар, очкын күзләр,
Ашытбаш бизәге лә.
Печән чапкан егетләрнең
Күзләре сездә генә.

Шифа булып җанга ята
Чәчәк исе, бал исе.
Челтер-челтер кызлар көлә,
Ямьләп авылым кичен.
Әй сез, кызлар, очкын күзләр,
Ашытбаш бизәге лә.
Гармун тарткан егетләрнең
Күңеле сездә генә.

Ямь өстенә ямьнәр өстәп,
Туйлар узар көзләрен.
Чит-ятларга бирмәбез без
Ашытбашның кызларын.
Әй сез, кызлар, очкын күзләр,

Ашытбаш бизәге лә.
Тирә-як егетләренең
Өмете сездә генә.

*Июнь, 2000*

## Мине югалтырга ашыкма*

Чишен, әйдә, сал өстеңне
Ун минутка булса да,
Кырык эшең кырык якка
Кырылырга торса да.

Кушымта:
Дусмы соң без, юкмы?
Үпкәләшер чакмы?
Мине югалтырга
Ашыкма шулчаклы.

Кермә тик узып барышлый,
Кил минем янга атап,
Өзелеп сагынган чагыңда
Бар мәшәкатең ташлап.

Кушымта.

Күрсәтмә күз яшьләреңне,
Елап килсәң, дәшмим дә.
Син минеке булсаң әгәр,
Таммас бөртек яшең дә.

Кушымта.

*2000*

## Минем арттан йөрмә, хыянәт*

Әсир итә очкын күзләрең,
Таң калдыра ялкын сүзләрең.
Җуяр идем, бәлки, акылым —
Йөрәгең таш синең, матурым.

Кушымта:
Куеныма кереп елышма,
Ышандырам диеп тырышма.
Йөрәгемдә яши Мәхәббәт,
Минем арттан йөрмә, хыянәт.

Мәхәббәтнең туган көнендә
Чакырылмаган кунак син генә,
Түбән булма инде шулчаклы —
Оныт минем янга сукмакны.

Кушымта.

Серле йозак белән бикләрмен,
Чит берәүне җанга кертмәмен.
Юлларыңа синең ак җәймә —
Үз тиңеңне эзләп тап, әйдә.

Кушымта.

*2001*

## Мин сезне кунакка чакырам*

Мин сезне кунакка чакырам —
Очрашып торабыз бик сирәк.
Күңелем моңланып тулганда,
Җырларым тыңларга сез кирәк.

Кушымта:

Хуш киләсез, рәхим итегез!
Күңелемнең түреннән үтегез.
Моң — дәва сагышлы йөрәккә,
Җырларым өләшәм бүләккә.

Мин сезне кунакка чакырам —
Килмичә калмагыз, мин көтәм.
Таңгача утырыйк җырлашып,
Без моңлы җаннарга шул җиткән.

Кушымта.

Мин сезне кунакка чакырам —
Бар булган кайгылар онытылсын.
Уятып тәүге яз гөлләрен,
Дөньяга сихерле моң тулсын.

Кушымта.

*2001*

## Ялгышма*

Парын эзләп очкан ак күгәрчен
Ялгышкандыр юлын, күрәсең.
Ул үзе дә белгәндерме-юкмы
Учларыңа очып керәсен.

Кушымта:

Тик адашып килгән бәхетеңне
Күрмәмешкә юри салышма!
Бер табылгач, инде югалмас дип,
Ялгышма син берүк, ялгышма.

Очрашуны көтеп көннәр озын,
Сөю-назлау көтеп төнозын,
Җаны белән күккә омтылса да,
Ул калдырып китми ялгызың.

Кушымта.

Дөньяларың онытып ни уйлыйсың,
Төннәреңдә нигә елыйсың,
Тиңен эзләп очкан кошчыгыңның
Учларыңа кысып җылысын?

Кушымта.

*2002*

## Сажидәкәй*

*Укытучы Сажидә апа Сафиуллинага*

Сажидәкәй! Моңлы карашыңда
Үпкәләү дә, тирән сагыш та.
Чәчәк кебек чакта тол калгансың,
Елый-елый рәнҗеп язмышка.

Кушымта:
Газизеңнең якты эзе яши
Кыз-улларың йөргән һәр җирдә.
Йөз аклыгың алар, йөз шатлыгың —
Син бит ялгыз түгел, Сажидә.

Кага-суга тормыш елатканда,
Каян алдың көч һәм сабырлык?!
Синең кебек батыр әнкәйләргә
Алтыннардан һәйкәл салырлык.

Кушымта.

Синең сөю — бер һәм гомерлеккә,
Еллар уза — сүнәм дими ул.
Дөньялыктан мәңгелеккә күчәр —
Чын мәхәббәт ике килми шул.

Кушымта.

*2003*

## Яшерен чишмәм*

Челтер-челтер көлеп, терекөмеш кебек,
Учларымнан качма йөгереп,
Сине, яшерен чишмәм, мин озак эзләдем,
Бер йотым назыңа тилмереп.

Кушымта:
Ярсый йөрәк, дөрли йөрәк.
Янган йөрәгемә ни кирәк?
Янып көлгә калмас өчен,
Яшерен чишмәм, миңа син кирәк.

Әйтмәсәң дә беләм: синдә дә бар сагыш,
Үзәкләрне өзә тавышың.
Җырыбыз бер икән, моңыбыз бер икән,
Булмаса да гәрчә кавышып.

Кушымта.

Сусаудан чатнаган иренемә бер тамгач,
Килмә бүтән, диеп озатма.
Татыйм бәхетемне тамчы-тамчы гына,
Җитсен диеп озак-озакка.

Кушымта.

*2003*

## Өч Пошалым — өч игезәк*

«Поши аулыйм» дигән сүздән
Исем алган Пошалым.
Түбән, Урта, Югарысы —
Өчесе бик дус аның.
Яши шулай гомер буе
Өч Пошалым бер булып.
Дуслык буыннан буынга
Күчсен гүзәл җыр булып.

Кушымта:

Эх, Пошалым чанасы ла,
Җәйләр җитсә — арбасы.
Җырлап үтсәң, сизелми дә
Өч Пошалым арасы.

Пошалымның осталары
Кулында ут уйната.
Бездәге таң әтәчләрен
Пычкы җыры уята.
Сүзгә тапкыр, эшкә маһир —
Заманча яшьләр бездә.
Безнең якка кияүгә чык,
Безнең яктан кыз күзлә.

Кушымта.

Тимерша аланына кил,
Балланып җиләк пешкәч.
Тәннәреңә сихәт керер,
Сул(ы) аланда су эчкәч.
Күз чагыла Карлыярда,
Ак кар яткан чагында.
Өч Пошалым — өч игезәк
Туган җир кочагында.

Кушымта.

*2004*

## Солдат егеткә*

Туган яктан, туган җирләрдән
Солдат егет көтә гел хәбәр.
Сөйгән кызы язган соңгы хат
Ник кадерле икән шулкадәр?!

Кушымта:

Көннәр-төннәр имин үтсен,
Әйбәт кенә хезмәт ит син,
Дусларыңа бездән сәлам әйт.
Сагынам сине, солдат егет,
Бер көн миңа бер ел кебек,
Исән йөреп, тизрәк өйгә кайт.

Газиз әткәң, сагынып бөркетен,
Күз яшьләрен сөртә яшереп.
Газиз әнкәң, улым кайтыр дип,
Көтә тәмле ашлар пешереп.

Кушымта.

Берәүгә дә әйтмә серемне,
Сөйгәнеңнән сиңа бар бүләк:
Уртак вәгъдәбезнең билгесе —
Туебызга тегәм ак күлмәк.

Кушымта.

*2004*

## Иң матур бәйрәмеңә

Бүләк булып барсын җырым
Иң матур бәйрәмеңә.
Ак теләкләр кушып бирәм
Ак гөлләр бәйләменә.

Кушымта:

Син миңа һәрвакыт кирәк,
Син янда чакта рәхәт.
Бу дөньяга туган өчен,
Булганың өчен рәхмәт.

Тормыш гүзәл, яшәү — бәхет,
Белсәң генә кадерен.
Югалтма бәхет-шатлыкның
Сиңа килгән кадәрен.

Кушымта.

Башлаган һәр яңа эшең
Син теләгәнчә барсын.
Гомереңнең һәрбер көне
Туган көн кебек булсын.

Кушымта.

*2005*

## Мәңгелек бәхәс*

Акыллы һәм чибәр идек,
Әдәп саклап кына йөрдек
Без сезнең яшьтә, дисез.
Күпме генә орышсак та,
Үзгәртергә тырышсак та,
Сез хәзер башка, дисез.

Кушымта:

Әй, этиләр-әниләр,
Борчылмагыз сез юкка.
Сүз әйтмәгез без яшьләргә,
Бу мәңгелек бәхәсләргә
Куярга иде нокта.

Сездән туган уллар икән,
Сездән туган кызлар икән,
Без начар булалмабыз.
Сезнең алмагачта үскән,
Үсү белән сикереп төшкән
Без алтын багалмагыз.

Кушымта.

Хыялларга ирек кирәк,
Күкрәктәге шашкын йөрәк
Азатлык даулап тибә.
Туу беләң зиһен керсә,
Акыл бездән алда йөрсә,
Яшьлек-юләрлек нигә?

Кушымта.

*2005*

## Язмышым минем — Арчам*

Алтын куллы балалары
Йөрәк җылысын биргәч,
Безнең Арча гөлбакчадай
Яшәрә язлар килгәч.
Данлы Арча, яңа Арча —
Халкымның йөз аклыгы.
Сабантуйлар булып гөрли
Тыныч хезмәт шатлыгы.

Аз булмады гомеркәйнең
Ут уйнаткан чаклары;
Сынауларның, баш идереп,
Бер елаткан чаклары.
Яшәвемә көч өстәүче
Сулышым минем — Арчам.
Туган ягым, горурлыгым,
Язмышым минем — Арчам.

*Июнь, 2005*

## Хуш килдең, Яңа ел!*

Йөрәкне җилкетеп, хисләрне уйнатып,
Өр-яңа ел килә илемә-җиремә.
Утларын яктыртып, йолдызлар балкытып,
Чакыра ул безне балачак иленә.
Яңа ел — могҗиза,
Яңа ел ул — тылсым.
Яшәсен елмаю,
Күз яше онытылсын!

Әкият дөньясы сихерле күңелне.
Без — аның кунагы, без — аның патшасы.
Теләкләр ак булса, ниятләр саф булса,
Беләбез хыялның тормышка ашасын.
Яңа ел — могҗиза,
Яңа ел ул — тылсым.
Яшәсен изгелек,
Өметләр аклансын!

Тугрылык һәм бәхет атлыйлар янәшә,
Дөньяны яшәтә мәңгелек мәхәббәт.
Хуш килдең, Яңа ел, рәхим ит, түрдән уз!
Хуш инде, Иске ел, барысына мең рәхмәт!
Яңа ел — могҗиза,
Яңа ел ул — тылсым.

Яшәсен мәхәббәт,
Бәхетләр мул булсын!

*Декабрь, 2005*

## Мин монда юк

Әллә күкләрдә кояш, әллә күкрәктә кояш?
Йөрәкнең дөрләп янган мәле...
Таныш йөзләр ят кебек, күңел тулпар ат кебек —
Шулдыр, күрәсең, сөю хәле.
Сорау бирмәгез. «Ниләр булды?» димәгез.
Хыялый дип көлмәгез, кадап җанга ук.
Мин бик ерак:
Җиде таулар артында,
Җиде диңгез артында.
Мин бит монда юк. Юк!

Анда ал гөлләр үсә, балдай хөрмәләр пешә,
Былбыллар иңгә кунып сайрый.
Иркә боландай ярым, үземә насыйп парым
Бишек үрергә гөлләр сайлый.
Сорау бирмәгез. «Кайда соң син?» димәгез.
Хыялый дип көлмәгез, кадап җанга ук.
Мин бик ерак:
Серле сөю илендә,
Йөзәм бәхет күлендә.
Мин бит монда юк. Юк!

*2006*

## Йөрәгеңнән йөрәгемә

Җем-җем карның аклыгыннан
Бигрәк якты кышкы кичләр.
Өермәдәй уйный-уйный
Урап ала татлы хисләр.
Мизгелгә дә аерылмый
Аңлашалар безнең күзләр.
Ак келәмдә бизәк булып
Кавышалар безнең эзләр.

Араларны суыталмас зәмһәрир салкын,
Йөрәгеңнән йөрәгемә үрләде ялкын.

Сабыйлардай шаярышып,
Кар атыштык икәүләшеп.
Буранга да, давылга да
Керик бергә җитәкләшеп.
Эзебезнең җылысына
Салкын карлар яуса явар,
Ул эзләрдә, язлар җиткәч,
Алсу гөлләр шытып чыгар.

Безнең барыр юлыбызга
Әйтерсең лә энҗе сипкән.
Күңелдә дә аклык-сафлык,
Сәбәпчесе кышлар микән?
Кар-йолдызлар учлап алып,
Көлә-көлә, күккә чөям.
Мин бит сине сөям, дисең,

Ә мин сине ныграк сөям.

Араларны суыталмас зәмһәрир салкын,
Йөрәгеңнән йөрәгемә үрләде ялкын.

*Ноябрь, 2006*

## Дөнья*

Таш кыя да сыкрап куя кайчак —
Ирләр була белик, димәгез.
Ирләр елый, елый алар сирәк,
Еласыннар, әйдә, тимәгез.

Кушымта:
Иелмәстәй башларны да
Хәсрәтләргә сала дөнья.
Зур кайгыны күтәрерлек
Көчләр бирә ала дөнья.

Бөркетләр дә, канатлары талгач,
Кунып тора кыя ташына.
Таянырлык көчле иңнәр кирәк,
Зарлы уйлар төшсә башыңа.

Кушымта.

Давыллары куба, бураннары, —
Балкып кояш чыга аннары.
Сынауларын юллый, ахры, язмыш,
Пакьләр өчен безнең җаннарны.

Кушымта.

*21 декабрь, 2006*

## Үкенмим*

Назлы итеп карама син, карама,
Берни дә юк хәзер безнең арада.
Онытыйк, дип, бәгърем, үткәннәрне,
Кагылма син төзәлмәгән ярага.

Кушымта:
Юк, үкенмим, мин барыбер үкенмим,
Оныттыр, дип синнән үтенмим.
Син — мәңгелек ярым,
Син — мәңгелек ярам...
Онытырга сине мөмкинме соң?

Үз кулларым белән бирдем ятларга,
Күз алалмыйм син яшәгән яклардан.
Сер бирмәскә, бәгърем, теләсәм дә,
Мин ваз кичмим син янымда чаклардан.

Кушымта.

Назлы итеп карама син, карама,
Кагылма син төзәлмәгән ярага.
Кайтып булса, бәгърем, үткәннәргә,

Җил дә кермәс иде безнең арага.

Кушымта.

*23 март, 2007*

## Син — мәхәббәтнең үзе

Син — мәхәббәтнең үзе,
Син — кичермәгән хисем.
Дөньяда иң матур сүз —
Син йөрткән нурлы исем.

Кушымта:
Энҗе ташлар белән бизәп,
Таҗ кидермим истәлеккә.
Исемеңне йөрәгемә
Язып куйдым гомерлеккә.

Син — ачылмаган гөлем,
Син — татымаган назым,
Көттереп, сагындырып,
Яшьлектән килгән язым.

Кушымта.

Син — тыңламаган көем,
Мин — ятланмаган шигырь...
Без — гүзәл бер җыр булып
Кушылган ике гомер.

Кушымта.

*1 апрель, 2007*

## Сәбәпләрен сора йөрәктән*

Ни сәбәпле мине яратасың, дип
Сорама син, кабат сорама.
Сине гашыйк иткән сәбәпләр эзләп,
Йөзләремә сынап карама.

Кушымта:
Яратам мин сине, бары яратам,
Җаннарыма якын күргәнгә.
Яшерен серләремне ачам ышанып,
Синең яратканны белгәнгә.

Серләреңне сорап торасы да юк,
Укып була, дисең, күзеңнән.
Энҗеләре тирән, ә күзләремдә
Чайпалганы гына күңелдән.

Кушымта.

Буйсынмыйча миңа, ихлас хисләрем
Җырлар булып чыга күкрәктән.
Йөрәгем бит сине, сине сайлады,
Сәбәпләрен сора йөрәктән.

Кушымта.

*2007*

## Тик син кирәк*

Әйлән-бәйлән уйный гүя дөнья,
Тормыш бит ул тоташ бәйрәм түгел.
Шатлыкта да, авыр вакытта да
Тигез сөю өмет итә күңел.

Кушымта:

Очар канат куя шатлык хисем,
Сөюемнән алам яшәү көчен.
Рәхмәт сиңа, рәхмәт, газиз кешем,
Минем бәхетемә туган өчен.

Ерак араларны якын итеп,
Кара төнне көнгә авыштырып,
Йөрәгемне бәйләп йөрәгеңә,
Сөю яши, безне кавыштырып.

Кушымта.

Җан сулышын, әйдә, уртак итик,
Бер-беребез өчен булыйк терәк.
Яшьлектә дә, гомер көземдә дә
Тик син кирәк миңа, тик син кирәк.

Кушымта.

*25 апрель, 2007*

## «Яратам» дип әйтсәң, ни була?*

Кыяга сыенып моңсуланып үскән
Ялгыз гөлдәй тоям үземне.
Җил-яңгырдан саклап, яшәсәң дә яклап,
Кызганасың назлы сүзеңне.

Кушымта:

Уттай челләләрдә сусаудан тилмереп
Чәчәк аткан гөлләр тиз сула...
Янган йөрәгемнең ярсуларын басып,
«Яратам» дип әйтсәң, ни була?

Күңелемдә — рәшә, җанымда — аҗаган,
Күрмисең шул, берни күрмисең.
Назың көтеп яшим, кочагыңда өшим —
Нигә бер уч җылы бирмисең?

Кушымта.

Бер елыйм, бер көләм, бер янам, бер сүнәм,
Кабынам да янә сүреләм...
Сөю тулы назлы карашыңны күреп,
Өметләнеп кабат тереләм.

Кушымта.

*29 апрель, 2007*

## Гомер юлын узыйк бергәләп

Карыйм әле, карыйм бер туйганчы,
Күзләреңнән алмый күзләрем.
Күпме йөзләр, күзләр арасыннан
Мин бит сине озак эзләдем.

Учларыңны куй син учларыма,
Йөрәгемә күчсен җылысы.
Башка куллар мине назламасын,
Синең куллар иң-иң назлысы.

Сөйлим әле, сөйлим серләремне,
Чит-ятларга серем чишмәдем.
«Яратам» дип өзелеп әйтер өчен
Мин бит сине көтеп яшәдем.

Кал, кадерлем, кал син яннарымда,
Китмә җаннарымны телгәләп.
Минутларны, сәгатьләрне түгел,
Гомерләрне кичик бергәләп.
Гомер юлын узыйк бергәләп.

*29 июнь, 2007*

## Бергә булуларга ни җитә?

Очраштырды безне тәкъдирме,
Кисештерде барыр юлларны?
Бәйләде ул чәчкә чәчләрне,
Кичегез, дип, ут һәм суларны.

Кушымта:

Тормыш сукмаклары борма-борма,
Язмыш чатларында ни көтә?
Авыр сынауларга бирешмичә
Бергә булуларга ни җитә?

Ятлар куенында — гөлбакча,
Барып керсәң — куе карурман.
Карурманга кереп адашкач,
Чыгар юлны кем соң табалган?

Кушымта.

Болыт артларында кояш бар,
Болгана да сулар бер тына.
Соңгы сүзне әйтмик ашыгып,
Сабыр итик сөю хакына.

Кушымта.

*1 июль, 2007*

## Озаклама*

Эшең сәбәп итеп,
Югаласың китеп,
Сагышланып сулсын дисеңме?

Бүлмәмдәге гөлләр
Башын түбән иде,
Күтәралмый сагыну хисемне.

Кушымта:
Юксынырга бирмә, ара ерак димә...
Өзелеп көткән кешең барында.
Нигә кирәк сүзләр? Аңлашсыннар күзләр…
Озаклама, кайт син яныма.

Бергә чакның кадерен
Аңлар өчен, бәгърем,
Янып-көю кирәк дисеңме?
Диңгездәге бозлар
Эреп бетәр иде,
Суга салсам сагыну хисемне.

Кушымта.

Беләм: күпкә түгел,
Барыбер көтә күңел —
Сабыр итү җиңел дисеңме?
«Яратам» дип әйтмә,
Көч-хәл җиңеп торам
Сиңа булган сагыну хисемне.

Кушымта.

*12 июль, 2007*

## Йөрәгемә яздым исемеңне

Гөлләр белән яздым исемеңне —
Шаулап чәчәк атты гөлләрем.
Күзләр җиткәч сулды чәчәкләрем —
Минем сөюемне белмәдең.

Кушымта:
Таш кадәрле ташны вакыт юа,
Агач, янса, кала күмергә.
Йөрәгемә яздым исемеңне
Җуелмаслык итеп гомергә.

Моңлы көйгә салган матур исемең
Кыңгыраулар булып чыңлады.
Тик син түгел, аны адашларың
Үзенеке итеп тыңлады.

Кушымта.

Яфрак белән күлгә тезгән исемең
Шаян дулкын китте таратып...
Исемеңне, күзләреңә карап,
Мин үзеңә дәштем яратып.

Кушымта.

*24 июль, 2007*

## Кардәшлекне саклыйк йөрәктә

## Каз бәбкәсе саклый әни

Каз бәбкәсе саклый әни
Чирәмдә, су буенда.
Төпчек кызы үсеп җиткән,
Бүләк кирәк туена.

Борынгыдан калган йола —
Туй табыны мул булыр.
Каклаган каз, мамык мендәр —
Иң зур бүләк шул булыр.

Буйга җиткән сылу кызлар
Читләргә китә «очып»,
Килен булып төшәр кызың,
Мамык мендәргә басып.

Яшь кәләшнең мендәрләре
Каз мамыгы — күбектән.
Бүген аңа яучы килгән
Лачын кебек егеттән.

*1999*

## Кайту

Ялантәпи баскан эзләремнең
Җылысына карлар яугандыр.
Авыл башындагы нәни инеш
Кар көртенә күмелеп калгандыр.

Әй язмышым, аерып туган йорттан,
Еракларга алып киттең син.
Карашларга — сагыш, ә йөзләргә
Сагыну төсе салып үттең син.

Бер ягымлы тавыш дәшә сыман,
Бик ерактан, хәтер түреннән.
Ромашкалы җәе яшьлегемнең
Ап-ак бәскә инде төренгән.

Ак бүреген кырын салды микән
Басуларда эскерт өсләре?
Таралгандыр иртүк урамнарга
Яңа пешкән икмәк исләре.

Әткәемнән откан «Арча» көен
Сагынып җырлармын дип кем белгән.
Кайтып киләм әле, кыяр-кыймас,
Күптән чыгып киткән юл белән.

*1999*

## Уйлану

Әй кыз бала, кыз бала,
Моңаймале, түз, бала.
Юксынып туган йортын,
Гомер итә кыз бала.

Чиксез уйларымны кушып,

Җеп эрлим җырлый-җырлый.
Кулымда әни орчыгы
Әйләнә зырлый-зырлый.

Төн йокылары күрмәгән
Әнием яшь чагында.
Кул җылыларын тоям күк
Шул җитез орчыгында.

Чорналган җептәй гомерләр,
Чуалды заманалар.
Уйлармы туган нигез дип
Без үстергән балалар?

*1999*

## Әнием хатлары

Була минем бик бәхетле көннәр,
Була моңсуланган чакларым.
Шатлыкта да, авыр вакытта да
Укыйм әниемнең хатларын.

Теләп миңа күркәм сабырлыклар,
Кушсаң да син, әни, түзәргә,
Күз яшьләрең тамган эзләр калган
«Бик сагынам» дигән сүзләрдә.

«Быел язгы ташу иртә төште,
Юлга чыкма, балам», — дигәнсең.
Хат соңында үзең: «Тиз көннәрдә
Күрешү көтеп калам», — дигәнсең.

«Бәрәңгеләр әйбәт булды, диләр,
Чыгып күрә алмыйм мин генә.
Сабый бала карагандай карый,
Мең рәхмәтләр яусын киленгә...»

Әниемнән хатлар килми инде,
«Кайт, балам» дип хәзер дәшми ул.
Бәхил булып, хәер-дога укып,
Сагыну хатларында яши ул.

*2000*

## Туган яклар җанга дәва

Кайларга китеп барасың,
Утыртчы, дустым поезд!
Хәсрәтләремнең куенында
Калдырма мине ялгыз.

Булмасмы ерак җирләрдә
Хәлемә керүчеләр,
Өзгәләнгән минутымда
Бер киңәш бирүчеләр?

Сагышлы йөзем күрмәсен
Якыннар да, ятлар да.
Сөенмәсен дошманнарым
Мин көенгән чакларда.

Нигә ашыгасың, поезд?
Ерагая тавышың.
Кемнәргә сөйләп бушатыйм
Күкрәк тулы сагышым.

Сыенам якын дусларга —
Бүтән чарам калмады:
Үзең күтәр кайгыңны, дип,
Поезд мине алмады.

«Туган яклар җанга дәва»
Диюләре чындыр ул,
Илләреңнән аерылсаң,
Бер хәсрәтең ун булыр.

*2000*

## Очрашу җыры

Сагынып килдегезме, сабакташлар,
Онытылмас Арча якларын,
Искә алырга дип гомеркәйнең
Бер кайгысыз үткән чакларын?

Хатирәләр — күңел түрләрендә,
Бер серләшик таңга кадәрле.
Бүген бездә Яшьлек үзе кунак,
Бу очрашу шуңа кадерле.

Сау гынамы, газиз укытучым,
Таныйсыңмы мине, юк микән?
Җан сыкравы булып кемдер дәште:
«Кайберәүләр инде юк күптән...»

Бәхилләшмик, бары саубуллашыйк
Аерылышып киткән чагында...
Бу изге йорт туган нигез кебек
Очраштырыр безне тагын да.

*2001*

## Мин — туган як баласы

Мин — Арчамда үз ягымның
Газиз йөрәк парәсе.
Ә читләргә чыгып китсәм,
Татарстан баласы.

Үземнеке була Мөслим,
Баулысы, Тәтеше дә.
Чит җирләрдә туганың күк
Үз ягың кешесе дә.

Сагынам Мишә талларын,
Ямьле Ык буйларын да,
Чупырдап үскән булсам да
Кесмәсем суларында.

Туган як — республикамның

Һәр авылы, каласы.
Мин — халкымның бер бөртеге —
Татарстан баласы.

*2002*

## Кошлар кайта

Әллә үтте кыр казлары,
Кыйгак-кыйгак сәлам биреп.
Әллә күктә ефәк тасма
Җилфердәвен калдым күреп.

Киек казлар, парын табып,
Оя кора туган якта.
Нәсел җебен ялгар өчен
Туган якка кошлар кайта.

Санарга да өлгермәдем —
Күмелделәр офыкларга.
Киек коштай бәйсез жанны
Җилкендереп очышларга.

Әйтерсең лә кыр казлары
Җырлап үтте турыбыздан:
«Өзелмәсен тамырыгыз
Туган-үскән ягыбыздан».

*10 май, 2008*

## Авыл баласы

Шәһәр тормышына ияләштем,
Миннән бәхетлерәк юк сыман.
Тик барыбер ялантәпи йөргән
Авылым урамнарын юксынам.

Телефоннан була шалтыратып,
Хат язалам, әгәр теләсәм...
Җаннарыма тынгы тапмыйм һич тә,
Бер авылга кайтып килмәсәм.

Берничә тел беләм, илләр гизәм —
Заманадан булмый калышып.
Тик гомергә керде күңелемә
Урман шавы, чишмә тавышы.

«Шәһәр кызы түгелмени син?» — дип,
Ник шулкадәр хәйран каласың?
Асылына алып кайта язлар
Җирсеп яшәр адәм баласын.

*Март, 2004*

## Озакламыйм

Төшләремә күптән керми туган йорт,
Кайтмый диеп инде өмет өзгәндер.
Күрешүне көтеп сабыр май ае
Юл буена сары чәчәк тезгәндер.

Элеккечә мине әни җанашым
Капка төбендә үк каршы алмас шул...
Озак тордың, хәбәр бирми тилмерттең,
Һай балам, дип өзелүче булмас шул.
Язлар җитсә, күңелдә боз кузгала,
Дәрьялары тула күзгә яшь булып.
Сагынулар-саргаюлар газаплый
Бәгырькәйдә яткан ачы таш булып.

Озакламыйм, кайтып киләм авылга,
Тынгы эзләп җанымдагы давылга.

*Март, 2004*

## Бөекләү

Язлар белән кайтты Арчаларга
Бөркет кебек мәгърур дүрт улы.
Ватан йөрәгендә урын алды
Һәйкәл-сыннар булып бу юлы.

Шушы туфрактан бит милләтемнең
Гали улларының күпмесе!
Даһиларның, галим-остазларның
Бу бөркетләр бары дүртесе.

Тукаена, Гомәр, Гарифына,
Мөхәммәткә баглап хөрмәтен,
Арчалылар шулай бөекләде
Туган халкын, газиз милләтен.

*26 апрель, 2004*

## Арча сөйли!

Арча сөйли! Шәфәкъ алсуланып
Таң туганда газиз җиремдә.
Башлап сүзен изге теләкләрдән,
Аваз сала Тукай телендә.

Тәүге сәлам авыл кешесенә,
Таңнан торучыга һәр көнне.
Терлекчегә, иген игүчегә —
Сыйлы итүчегә һәркемне.

Хәерле көн хезмәт юлларыннан
Бергә атлаучыга ил белән.
Алны-ялны белми чабучыга,
Ашын табучыга тир белән.

Иман бирсен намазлыкка баскан
Уңай нияттәге җаннарга.
Тәмле төшләр күрсен нарасыйлар,
Изрәп йоклаганда таңнарда.

Гыйлем эстәүчегә — тел ачкычы,
Мөгаллимгә — зиһен, сабырлык.
Адашканның ачсын күңел күзен,
Туры юлны эзләп табарлык.

Әткәй-әнкәйләргә килеп торсын
Балаларның изге хәбәре.
Җитәкчеләр илгә игелек кылсын
Кулларыннан килгән кадәрле...

Арча сөйли! Сөйләп кенә калмый,
Сүзе күчә изге гамәлгә.
Арча сөйли! Сайлап киләчәкне
Тавыш бирә бөтен галәмгә.

*30 ноябрь, 2004*

## Кардәшлекне саклыйк йөрәктә

Бер анадан туган булмасак та,
Бер туфракта туып үстек без.
Туган авыл күкрәгеннән типкән
Чишмәләрнең суын эчтек без.

Очрашабыз хәзер сирәк кенә,
Эчәр сулар читтә булганга.
Авылым хәбәрләре җанга дәва,
Сагынулардан күңел тулганда.

Бер сукмактан тәпи атлап киттек,
Бер мәктәптә гыйлем алдык без.
Нинди генә үрләр яуласак та,
Авылдашлар булып калдык без.

Очрашабыз хәзер сирәк кенә,
Җыяр ризык читтә булганга.
Авылым һавалары җанга дәва,
Сагынулардан күңел тулганда.

Туган нигез җылысына төреп,
Кардәшлекне саклыйк йөрәктә.
Үз-үзенә кайта һәрберебез
Туган якта, туган төбәктә.

Очрашабыз хәзер сирәк кенә,
Тәкъдиребез читтә булганга.
Авылым кешеләре җанга дәва,
Сагынулардан күңел тулганда.

*21 февраль, 2007*

**Эчтәлек**

Пар алмадай идек, багалмадай... *Г.Морат* ……

**Кешелегем**

Ялгызларга ........................
Көз һәм без .......................
Бергә чакның кадерен белик ..............
Тормыш киносы .....................
Хуш хәзергә... .....................
«Мин яңадан тудым бу дөньяга...» ...........
«Шигырем, дускаем, ничекләр син булдың?!.» .....
Исәнме, яңа көн! ....................
Җырчы кош ........................
Кычкыра күке, кычкыра .................
Гыйнвар төне ......................
Икетеллелек ......................

«Бераз гыйбрәт алсын, диеп...» .............
Гадел хаким .......................
Кешелегем ........................
Төен ...........................
Иманыңа куәт сора ...................
Аңла, балам... ......................
Кабан елы ........................
«— Хәзер болай сөйләшмиләр...» ...........
Белмәү кирәк .......................
Аерылу ..........................
Моңаймале ялгыз, и балам... ..............
Сәфәр ..........................
Парлы гомер ......................

**Саумы, яшьлек!**

Аклык ...........................
Кил генә ..........................
Ачы язмыш ........................
Ни булса, шул! ......................
Чынлап шаяру ......................
Күңелемнән күңеленә ..................
Хәтәр төш ........................
Килә үзем булып каласым ................
Мәхәббәтем гафу итәр микән? .............
Җәй ............................
Мин бәхетле булыр өчен тудым ............
Тәүге кар .........................
Тормыш — тамаша ...................
Мәхәббәт җимеше ...................
Зәңгәр күлдә .......................
Газаплама ........................
Мин, чыннан да, сөя идем ................
Йөрәгеңне куй син йөрәгемә ..............
Мәхәббәт бишеге ....................
Дускаем-сердәшем ...................
Ышанам .........................
Моңлану .........................
Китү ...........................
Гөлбадран ........................
Аңлашмыйча аерылыштык ...............
Ярый син бар .......................
Кушылыйк куш каеннардай ...............
«Күпме сүз сөйләнде, вәгъдәләр эчелде...» .......
«Миңа сусап баккан карашыңда...» ..........
Ышандыр .........................
Ут һәм су .........................
Саумы, Яшьлек! .....................
Үзем булып калыймчы! .................
Җаныма нидер җитми ..................
Бердәнберемә ......................
Безнең сөю ........................
«Бер-беребезне тагын үпкәләттек...» .........
Соңгы бүләк .......................
Мин синең өчен яратылганмын .............
«Әбелхәят чишмәсенең бер тамчысы...» .........
«Сез кая илтәсез, юлларым?..» ............
Ник дәшәсең? ......................
Агыла гомер, агыла ...................
Кичә һәм бүген ......................
Тормыш — сәхнә .....................
Очрар әле ........................
Хушлашу .........................
Сөйләшмик ярату турында ...............
«Каләмемнең кипте карасы...» .............
Янартавым ........................
Розалар .........................
Тәүге ярым ........................
Хакыйкать ........................

**Оч иреккә, җырым!**

Дәшмә миңа, соң инде... .................
Ялгыз әнкәй .......................
Кура җиләк ........................
Пар алма .........................
Балачагыма кайтам ...................
Моңаймагыз, шомыртларым ..............
Әйтер сүзең әйтеп кал .................
Чишмәләрдә керләр чайкыйм .............
Арчаларда калып булмады ...............
Син — башканың бәхете ................

Толымнарым ........................
Ялгыз учак .........................
Сары кашкарыйлар ..................
Ана җыры ..........................
Рәхмәт, Казаным .....................
Мәхәббәтле бул ......................
Мин ул, әни, синең яшь чагың ..............
Килә бүген ялгыз каласым ................
Оч иреккә, җырым! ....................
Син сөюдән чибәр .....................
Телефон дәшми ......................
Йөрәгемә карый күзләрең ................
Адаштык Мәхәббәт илендә ................
Күрше кызы ........................
Тылсымлы Мәхәббәт ....................
Алсу гөлем .........................
Кояшлы гомер .......................
Унҗиде яшь ........................
Әйдә, китик ерак-еракка... ................
Әнкәем-сердәшемә ....................
Әниемнең туган көне ...................
Син — матур җырым ....................
Безнең сөю .........................
Ни булды сиңа? ......................
Җавапсыз сөю .......................
Әткәй-әнкәй — пар канатым ...............
Дуслар кирәк һәрвакыт ..................
Яшьлегемә кире кайталмыйм ..............
Ашытбаш кызлары ....................
Мине югалтырга ашыкма ................
Минем арттан йөрмә, хыянәт ..............
Мин сезне кунакка чакырам ..............
Ялгышма ..........................
Саҗидәкәй .........................
Яшерен чишмәм .....................
Өч Пошалым — өч игезәк ................
Солдат егеткә .......................
Иң матур бәйрәмеңә ...................
Мәңгелек бәхәс ......................
Язмышым минем — Арчам ................
Хуш килдең, Яңа ел! ....................
Мин монда юк .......................
Йөрәгеңнән йөрәгемә ..................
Дөнья ............................
Үкенмим ..........................
Син — мәхәббәтнең үзе ..................
Сәбәпләрен сора йөрәктән ..............
Тик син кирәк ........................
«Яратам» дип әйтсәң, ни була? .............
Гомер юлын узыйк бергәләп ..............
Бергә булуларга ни җитә? ................
Озаклама .........................
Йөрәгемә яздым исемеңне ................

**Кардәшлекне саклыйк йөрәктә**

Каз бәбкәсе саклый әни ..................
Кайту ............................
Уйлану ...........................
Әнием хатлары ......................
Туган яклар җанга дәва .................
Очрашу җыры .......................
Мин — туган як баласы ..................
Кошлар кайта .......................
Авыл баласы ........................
Озакламыйм ........................
Бөекләү ...........................
Арча сөйли! ........................
Кардәшлекне саклыйк йөрәктә ............

Литературно-художественное издание

***Ахметзянова** Сания Юносовна*

# Пара яблок

Казань. Татарское книжное издательство. 2008
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Әхмәтҗанова** Сания Юныс кызы*

# Пар алма

Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Рәссамы *З.З.Хәкимов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Л.З.Шиһапова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.06.2008.
Форматы 70г90 $^1/_{32}$. Шартлы басма табагы 5,85.
Шартлы буяу-оттиск 6,14. Нәшер-хисап табагы 4,78.
Тиражы 2000 д. Заказ Т-669.

Татарстан китап нәшрияты ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
http://tatkniga.ru
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.